С(Баш)
Б99
аб

# БҮӘ БУЕ КАЕННАРЫ



Ч(Баш)
Б99

# БҮӘ БУЕ КАЕННАРЫ



Шигырьләр, хикәяләр, җырлар

39168-13193

МБС Янаульского
района ...

УФА
1996

84 Баш
А 48

**Авторлар коллективы**

А 48 Бүә буе каеннары. Хикәяләр, шигырьләр, җырлар. — Уфа: Яңавыл язучылар оешмасы. 1996. — 80 бит.

Яңавыл якларында каләм тибрәтүчеләр күп кенә. Бу җыентыкка шул төбәкләрдә яшәгән һәм иҗат иткән егермеләп авторның шигырьләре, хикәяләре һәм җырлары тупланды.

© Яңавыл язучылар оешмасы, 1996

## ИҖАТ ОФЫКЛАРЫ КИҢӘЯ

Тормыш ничек кенә катлаулы, авыр булмасын, кешеләр әдәбиятсыз, сәнгатьсез яши алмый. Тормышның бөтен кире якларын фаш итеп, ачып салган, шуның белән бергә изге тойгылар уяткан, яшәү дәртен үстергән, кеше күңеленә хозурлык китергән берләнбер чара — ул әдәбият.

1922 елның ноябрь аенда безнең төньяк-көнбатыш регионында яшәүче һәм иҗат итүчеләр өчен зур вакыйга булды: Яңавыл шәһәрендә язучылар оешмасы төзелде. Бу исә яшь иҗат көчләренә ярдәм күрсәтү нияте белән эшләнде. Бу очракта, нинди генә кыенлыклар булса да, кулга алган иҗат эшебезне җанландырырга, төрләндерергә тиеш булабыз. Әдәбият шәхескә дә, заманга да йогынты ясый. Мең яшә — мең өйрән, дигән безнең бабайлар. Безгә күп нәрсәгә өйрәнергә, тир түгеп иҗат итәргә кала.

Яшь оешманың эше көннән-көн төрләнә, иҗат офыкларыбыз киңәя бара. Урындагы язучылар, шагыйрьләр әдәбият сөючеләр белән әледән-әле очрашып, иҗат җимешләре белән уртаклашалар, даими рәвештә урындагы, республикадагы гәзит-журнал битләрендә, радио, телевидение аша чыгышлар ясыйлар.

Кыска гына вакыт эчендә Борай, Балтач, Яңавыл районнарында әдәбият көннәре үткәрелде. Уфадан бер төркем язучылар, шагыйрьләр: Равил Шаммас, Рәшит Низамов, Марат Кәримов, Фаек Мөхәммәтҗанов һәм башкалар катнашты. Яшь һәм башлап язучыларның иҗат конференцияләрен үткәрдек. Нәфисә Хәбибдиярова, Әкълимә Саяпова, Әсгать Галиев, Инсур Шәнгәрәев, Фәвәзит Әхмәтшин, Рәфисә Карамова, Камил Гәрәев, Фәнзия Максютоваларның кулъязмалары уңай бәяләнде, китап итеп чыгару өчен, нәшриятка тапшырырга дигән карар кабул ителде.

Хәзерге көндә иҗат кешесенә үз максатына җитү өчен төрле юллар эзләп карарга туры килә. Ничек кенә булмасын, без үзебезнең бөтен мөмкинлекләрдән дә файдаланып, бу проблеманы хәл итү юлларын табарга тиешбез. Язган әсәрләребезне дөньяга чыгарырга спонсорлар эзлибез. Һәр районда иҗат итүче, каләм тибрәтүче кешеләрне табарга була. Нефтекама шәһәрендә — «Инеш», Борайда — «Яшь бөреләр», Тәтешледә — «Тамчылар», Яңавылда «Замандаш» әдәби берләшмәләре эшләп килә. Килә-

чәктә башка районнарда шундый әдәби түгәрәкләрне оештырырга кирәк булачак.

Безнең арада иҗат эше белән шөгыльләнгән сугыш ветераннары да бар. Алар, олы яшьтә булсалар да, актив иҗат итәләр һәм әдәбият сөючеләр белән еш очрашып торалар. Әкълимә Саяпова, Касыйм Гайданов, Мәснәви Зәйнуллин, Фәрит Мөниров кебек үз укучыларын тапкан иҗатчылар әле булса дөньяга беренче китапларын чыгарганнары юк.

Каләм тибрәтеп караучылар — төрле профессия кешеләре, төрле урында эшлиләр, төрле яшьтә алар.

Бик еш кына гәзит-журнал битләрендә аларның шигырьләре, хикәяләре, җырлары басылып тора. Актив эшләгәннәр арасында Каһим Әүхәтов, Кәүсәрия Шәфыйкова, Нәфисә Хәбибдиярова, Әсгать Галиев, Инсур Шәнгәрәев, Зәниф Сәетов һәм башкалар бар.

Безнең иҗатчылар төрле жанрда эшлиләр, азмы-күпме тәҗрибә туплыйлар. Нечкә күңелле җаннар яшәгән урында җыр туа, шагыйрьләр туа.

Соңгы вакытта Яңавылга республикабызның күренекле язучылары, шагыйрьләре бик еш килеп тора. Башкортстанның халык шагыйрьләре Мостай Кәрим, Равил Бикбаев, шулай ук әдипләр Муса Гали, Динис Бүләков, Сафуан Әлибаев, Рафаэль Сафин, Муса Сираҗи, Марат Кәримов, Рәдиф Тимершин, Рәшит Низамов, Ирек Кинҗәбулатов, Нәҗип Асанбаев һәм башкалар булды безнең якларда.

Күренекле язучылар, шагыйрьләр белән очрашу-күрешү, аларның әдәби эшчәнлеге белән танышу башлап язучыларга иҗат осталыгына өйрәнергә мөмкинлек бирә.

Яңавылда «Замандаш» әдәбият берләшмәсенең уңышлы эшләп килүе бүгенге көндә иҗатчылар һәм әдәбият сөючеләр өчен дә зур әһәмияткә ия булып тора. Әдәби берләшмәнең эшчәнлеге яшьләргә әдәбият мәйданына аяк басарга форсат тудыра. «Замандашны заманча сурәтләргә» тәкъбире — әдәби берләшмә әгъзаларының девизы булып тора. Бүгенге үзгәртеп кору чоры шуны таләп итә.

Безнең «Замандаш» әдәби берләшмәсенең төзелүенә быел май аенда 15 ел тулды. Бу вакыйганы зурлап, тантаналы рәвештә үткәрдек. Район һәм шәһәр хакимияте башлыгы Н. З. Зиязов альманахны чыгару өчен акча белән ярдәм күрсәтергә ризалык бирде. «Бүә буе каеннары» дип исемләнгән җыентыкка Яңавылда яшәгән иҗатчыларның шигырьләре, хикәяләре, җырлары тупланды.

Бүгенге көндә кешеләргә җыр-моң өләшеп, уй-кичерешләрне уртаклашып яшәү көн үзегенә куелган таләпкә тәңгәл килә.

*Фәрит СУФИЯРОВ,*
*Яңавыл язучылар оешмасының җаваплы сәркатибе*

# ШИГЫРЬЛӘР

**ФӘРИТ СУФИЯРОВ**



## ОРАН САЛАМ

Күп сөйлисең, чамаларны белми,
Шуңа, энем, телдән табасың.
Дустан дошманыңны аер элек,
Кемнең тозагына кабарсың?

Үз телеңә хуҗа булу кирәк,
Кошлар кебек гел син сайрама,
Күргән-белгәнеңне сөйләп йөрмә,
Ирләрчә бул, артык сайланма.

Заманалар чуар, хәтәр чакта,
Үз өненә күпләр бикләнә.
Имансызлар, фахишәләр белән,
Күр, дөньялар ничек чүпләнә.

Җир өстенә чыккан үлән сыман,
Көнгә керсәң, арта вәхшилек.
Әүвәлгедән килгән йолаларны
Ник оныттык, кая яшердек?

Яңа гасыр капкасына кердек,
Әдәп бетә, нәрсә кала соң?
Бөтен көчне җыеп оран салсам,
Кемнәр мине дөрес аңлар соң?

* * *

Урал урманнарын кистем,
Күмер ташларын ваттым.
Хезмәт җимешләрен татыйм,
Бетмәс куаныч таптым.

Бәхетемне эзләп йөрдем,
Күз күрмәгән якларда.
И сагындым авылымны,
Җырлар яздым хатларга.

Өмет белән яшәгәнгә,
Җитә ихтыяр көче.
Авырлык кичергән саен
Түземле була кеше.

Тормыш сынап караганда
Сынмадым, сыгылмадым.
Ерак юлларда йөрсәм дә,
Мин арып егылмадым.

Ата-бабам изге эшен
Гомергә өлге иттем.
Язмышыма сокланырлык,
Ил күргән егет иттең.

## ЯЗМЫШ БЕЛӘН АЛЫШАМ

Яшәр өчен дәгъвалашам,
Якалашам, алышам.
Ир уртасына җиткәнмен,
Сынатмаска тырышам.

Кайчагында көтмәгәндә
Тәгәрим, төшәм түбән.
Өскә үрләгән чагымда
Күккә тиядер түбәм.

Канатсыз кош хәлендәмен,
Юк, киталмыйм качып та.
Хаксызлыкны күргән саен
Бәгырь әрни, ачыта.

Авыр йөкләр иңгә ята,
Килмәсә дә көчемнән.
Мин гаепле булмасам да,
Ояламын кешедән.

Дөньяның бар матурлыгын
Күреп яшәргә кирәк.
Таш ватыла, корыч сына —
Ышанам, түзә йөрәк.

Җил-давыллар каршы исә,
Аягымнан екканчы.
Язмыш белән алышырмын,
Тәннән җаным чыкканчы.

## ЮЛ ЙӨРЕП ГОМЕР УЗА

Арба тәгәрмәче сыман,
Алга тәгәри еллар.
Киләчәккә чакырып тора
Бормалы озын юллар.

Юлларым сүтелеп кала,
Кем чыгалыр очына?
Зәңгәр капкалар шикелле
Офыкларым ачыла.

Елларым белән юлларым
Үрелеп бергә бара.
Кеше гомере санаулы,
Еракмы барыр ара?

Җилләр исә, сулар ага,
Йөрәк майлары сыза.
Күренми дә, сизелми дә,
Юлларда гомер уза.

## ӘЙТЕРСЕҢ ЛӘ, БЕРНИ БУЛМАГАН

Йөзгә бәреп салкын җилләр исә,
Юлларымда очрый киртәләр.
И, газаплы борчуларга салып,
Күкрәү белән килә иртәләр.

Уңнан-сулдан, алдан-арттан кинәт,
Ташланалар этләр өере.
Нахак сүзләр йөрәгемә керде,
Ташлар булып калды төере.

Мәкерле һәм җинаятьче итеп
Кем яраткан адәм баласын?
Зинданнарга салган кешеләрне,
Каргаргамы аның анасын?

Хаксызлыктан җаным рәнҗетелә,
Утларында дөрләп янамын.
Үгисетелгән бер малай сыман,
Эндәшмичә кайчак каламын.

Берсен-берсе дуслар ашап бара,
Җае чыкса ятлар бәйләнә.
Әйтерсең лә, берни булмаган күк,
Җир күчәре буйлап әйләнә...

## БЕЗ АДАШТЫК

Саз уртасына төштекме,
Пычрандык һәм карайдык.
Бу тормышка аптырашып,
Бер-беребезгә карадык.

Нәрсә булганын белмәссең,
Каһәрле авыр заман.
Адаштык, йөдәшеп беттек,
Көйләнми дөнья һаман.

Кеше кадерләре калмый,
Ачудан каным кайный.
Түрәләр, куштаннар бар да,
Илем байлыгын талый.

Җир убылып төшә сыман,
Ыгы-зыгы калыкты.
Киләчәктә ниләр көтә —
Шомландыра халыкны.

Кеше язмышына кемнәр
Сузалар пычрак кулын?
Халкым азатлыгын юллый —
Ышанам, табар юлын.

## КӨНЧЕЛЛӘР КҮП

Күңел иркен, адашырлык,
Сәхрә кырга тиңләшә.
Дус күреп йөргән кешеләр
Күп чак миннән көнләшә.

Эт шикелле әрсез булган,
Мин беләм кешеләрне.
Таш ыргытып, ут йөгертеп,
Көн күргән көнчелләрне.

Аккан чишмәне корытыр,
Көнчелләр тапса көчне.
Бар булмышы, фигыле ни,
Мәкерле, кара эчле.

Гайбәт өсти якынына,
Күршесенә, дустына.
Дәрәҗәсе артмаса да,
Эреләнә, очына.

Кем итеп аны танырга,
Төрле битлекләр кигән?
Иманын сатып яшәргә
Безнең арага килгән.

## ҖЫР КАЛА

Вакыттан да өстен берни дә юк,
Бар галәмгә җитә әмере.
Еллар, айлар, көннәр белән чикле, —
Кеше гомерләре кадерле.

Вакыт хөкемендә язлар, көзләр,
Агар сулар, явар яңгырлар.
Басуларда шытар яшел уҗым,
Кошлар җыры һәрчак яңгырар.

Алсу шәфакъ сүнә, таң уяна,
Төн белән көн килә алмашып.
Үз вакыты җиткәч, ай-йолдызга
Сәфәр чыга кеше юл башлап.

Вакыт белән һәркем исәпләшә,
Биек таудан тигез җир кала.
Мәңгелеккә кемдер дәгъвалаша,
Бүләк итәм — миннән җыр кала.

## ТАНСЫК ЯЗЫМ

Кар сулары челтер-челтер ага,
Тау битләре көнгә ачыла.
Күкләр аяз, болыт әсәре юк,
Караш төшә офык очына.

Миңа тансык ташу сулар шавы,
Җиргә шыткан яшел чирәме.
Урман-кырлар уяналар инде,
Тирәкләрем серен сөйләде.

Биләүләрдә агач бөреләре,
Сөеп кенә җилләр тирбәтә.
Яз кешегә сөю алып килә,
Кабул булды минем теләк тә.

Җирнең төсе, яме арта бара,
Кабатланып тора гомергә.
Назларыңнан мине мәхрүм итмә,
Югалтасы килми һичбер дә.

Илгә кайтты кошлар ерак яктан,
Сайраулары җанга юл алды.
Сагышларым, шәүлә булып кына,
Күз алдымнан китеп югалды.

## ЯҢАВЫЛ

Яңавыл исемен кушкан,
Кемнәр шулай атаган?
Ата-бабам туган җирне
Һәрчак зурлап мактаган.

Көнгә керсәм бер яңалык
Арта тора дөньяда.
Биек йортлар үсеп чыга,
Юллар ята өр-яңа.

Яңавылда гел яңалык,
Изге уйлар кичерәм.
Сөенечен, куанычын,
Күңелемә күчерәм.

Дәртләндергеч яңа җырлар
Яңавылда языла.
Иҗат белән, хезмәт белән
Киләм тормыш язына.

Изге ниятә торабыз,
Киләчәк бәхет алда.
Уртак итеп шатлыкларны
Яшибез Яңавылда.



ӘКЪЛИМӘ САЯПОВА

## БАШКОРТСТАН

Башкортстан — җырчы илгенәм!
Ничә милләт синдә яралган,
Зур йөкләрне бергә күтәреп,
Көрәшләрдә бергә дан алган.
Башкортстан — гүзәл гөлстан!
Ирекле ләр белән юлларың...
Балкый синең якты уйларың,
Горурлана кыз һәм улларың.
Башкортстан — дуслык бишеге,
Мәңге күрмә күңел тарлыгын.
Акыл чәчеп яшә, нур биреп,
Яңгырасын данлы җырларың!

## АКЫЛ КИТЕР БЕЗГӘ, ЯҢА ЕЛ

Кояшлы көн, айлы төнең белән,
Нурлы йөзең белән кил безгә.
Көчтәнәчең булыр балаларга...
Бәхет сорап,
Мин дә кул сузам.
Бәхетсезлек — һаман кан коюлар.
Бәхетсезлек — хаклар артуы.
Туган җирне сату... Нәрсә кала?!
Тигезсезлек кире кайтуы...
Сорамыйбыз, гел яз китер, диеп,
Булыр елның көзе, кышы да.

Өши җаннар ачуланышудан,
Булсын күңел тарткан дусы да.
Тәнгә җылы кирәк, рухи көч.
Салкын кышны булсын җебетеп,
Күңелләрдә каткан калын бозны
Агызырлык булсын эретеп.
Яңа елым!
Безгә акыл китер!
Һәммәбезгә булсын җитәрлек.
Акылсызлар явын юл яздырып,
Яшәү йөген төяп үтәрлек.
Әй, Ходаем!
Булчы изгелекле?!
Яңа елга ярдәм кулың суз.
Яңа елның ак карлары кебек,
Саф күңелле,
Ак булыйкчы без!

## ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕ

Олы бәйрәм —
Кара кайгы катыш.
Аны ничек акка буярга?..
Күңел бәйрәм белән тулсын өчен,
Кайгы йөген кая куярга?
Әллә тилеримме хәмер эчеп,
Акыл йозагыннан ычкыныйм...
Уралтауның түбәсенә басып:
«Без — җиңүчеләр!» — дип кычкырыйм.
Дала чәчкәләрен җыярга да,
Каберләргә салып куярга...
Бәйрәм диеп тормый, йөрәк елый,
Күңелемне ничек тыярга?
Яшьлектәге кебек урам буйлап,
Кыллар чиртеп, җырлап үтимме?
«Сугыш адаштырды сөйгәнемне,
Кайтып керер», — диеп көтимме?
Җиңү көне илле яшькә җитте.
Сугыш калды минем йөрәктә.
Чәнчеп, кадап ала... Посып яши
Күңел куагында — тирәктә.
Аның өлешен дә куярга да,
Дусларны табынга җыярга.
Хыянәтсез бит ул минем хәтер...
Юксынып, моңаеп җырларга.

Җиһү көне нурлы, якты, җылы.
Җаным уйный. Җаным — күбәләк...
Гаҗәпмени, әгәр күз яшьләрем
Көмеш булып тамса тәгәрәп.

## ЯҢА ЯЗДА

Карлар эреп, ерганаклар агачак,
Җир яшәреп, яшьлегенә барачак.
Ал күлмәкле яңа таңнар туачак,
Салкын чаклар артта торып калачак.
Яңа язда яңа гөлләр үсәчәк,
Язмыш безгә тагын нәрсә бирәчәк?!
Көткән бәхет быел язмы киләчәк?
Кара күлмәк кидермәсме күрәчәк?
Кичтән көткән Кояш иртән киләчәк,
Көлеп күктән нурын Җиргә сибәчәк.
Орлыклары көзен кипкән гөлләрнең,
Беләм, тагын яңа шытым бирәчәк.
Безнең җаннар сөя язгы көннәрне,
Терелерме
Шиңгән күңел гөлләре?..

## УЗЫША ЯШЬЛЕК БЕЛӘН

Яши белми минем күңел
Килешеп яше белән:
Тынгы белми, бәхәсләшә,
Узыша яшьлек белән.
Яшь гомер очкынын өреп,
Күрәтмәкче күңелем.
Яшьлек уты кабат янмый, —
Сизми мөмкин түгелен.
Күңел тәрәзәсен чиртеп,
Җилләр гел моң уйната.
Таң нурлары күңелемдә
Яшәүгә дәрт уята.
Йөк тартырга булышыйм, дип,
Эшкә көйләнә күңел.
Гомерем юлын башларга
Аяк киенәм кебек.

## ЙОРТЫМНЫ ТУЗДЫРЫП КУЙМАСЫН

Өйләнешкәч, без йорт төзеп кердек,
Сөю хисен салып нигезгә.
Эсселәрдән, җил-давылдан саклый,
Бәхет сараедыр ул безгә!
Гомер буе яшәр өчен, дидек,
Мәхәббәттән үрдек бурасын.
Картаюны сизми, йортым япь-яшь,
Үзем кебек чыдам, күрәсең.
Кояш нурларының төсен алып,
Тышын буяп куйдым сарыга.
Алты почмаклы шул авыл өе
Көлеп торсын, дидем, барына.
Менә ничә еллар, сыңар калып,
Истәлекләр язам шул йортта.
Юк! Ялгызым түгел, һаман икәү,
Күңелдән китми ул минут та.
Икәү яшәргә, дип, йорт төзедек,
Мәхәббәттән үреп бурасын.
Җанда шик тудыра заман җиле
(Әллә нинди бит ул, уйласаң...),
Ярятышу чыкты модадан, дип,
Йортымны туздырып куймасын!

## СОҢ, ДИП ТОРМАС

Миннән дә бай тагын кем бар җирдә?
Күңелкәем тулы мәхәббәт.
Сөю, көю, яну, ялкынлану...
О, табигать!
Сиңа мең рәхмәт.
Ә син, язмыш!
Син бит хыянәтче.
Безне башка белән парладың.
Ярый әле минем күңелемнән
Сөю хисен урлый алмадың.
Йөздә җыерчыклар, чәчләр ап-ак,
Мәхәббәт яшь һаман күңелдә.
Очраштырма, Ходай,
Соң, дип тормас,
Кабыныр да китәр бүген дә.

КАСЫЙМ ГАЙДАНОВ



39168 - 28193

## И, ТУГАН ИЛ

Ярты дөньяны әйләндем,
Күрдем илнең төрлесен.
Тик тапмадым үз илемнән
Яктысын, кадерлесен.

Алтын, данга безнең буын
Сатыла торган түгел,
Ниятләр изге булуын
Таныттык эштә төгәл.

Илем өчен яшьлегемне,
Барлык көчемне бирдем,
Кирәк булгач гомеремне
Кызганмый утка кердем.

Калдыр, шагыйрь, карт Уралны,
Әйдә безгә, дисәләр,
Алыштырмам Ватанымны,
Хәтта оҗмах бирсәләр.

## СУГЫШТАН СОҢ

Фашистларны җиңгәч, сугыш беткәч,
Насыйп булгач илне күрергә,
Байгуҗама кайттым, сабан җиткәч,
Эй, ашыгам өйгә керергә...



ЦБС Янаульского
района Баш. АССР
абонемент

Ишле идек без сугышка кадәр,
Алты бала анам үстергән.
Дүрт туганны йотты юеш кабер,
Апамны да ачлык үтергән.

Җиңүләргә тик бер атна калгач,
Кайгысыннан үлгән әнкәем.
Туган йортта миңа җәйде колач
Исән калган гарип әткәем.

Чатан-солдат дустым ашка җыйган,
Шинель җәеп салкын түренә.
Шәраб тапкан, сыйлый, әй, изге җан,
Авызын ачса, үпкә күренә.

Сугыш эзе монда: дүрт-биш хатын
Сабан сөйри.., ял дип тормыйлар,
Яшь бер солдат кабык тубал тагып,
Бодай чәчә, картлар тырмыйлар.

Бага-чага эш өстендә укый,
Зурлар белән умач ашыйлар.
Көтү көтә алар, утау утый,
Буә буйдан утын ташыйлар.

Совет илен яклап үлеп калды
Авылымнан өч йөз ир-егет,
Күпме гарип, толлар, җимереклек,
Ә шулай да сүнми ак өмет.

Һәрбер нигез көтә газизләрен,
Кайтарырга юк бит бер чара,
Сөйгәненең эзләп эзкәйләрен,
Кая гына бармый бичара?!

Күпме газап илгә китерделәр
Гитлер яклы явыз фашистлар...
Без күргәнне яшьләр онытырмы,
Киләр буын алда ни эшләр?!

## ҮТКӘН ЮЛЛАРЫМ

Көтүче дә
Булдым, игенче дә,
Көрәш, дисәң,
Бездән кем узар...

Шигъри юлга чыктым
Җиденчедә,
Сугышларда солдат —
Нык усал...

Көньяк тауларыннан
Ничә үттем,
Җанга тиде
Котып салкыны,
Илне саклап
Гангутларга җиттем,
Рейхстагка
Имзам салынды.

Вузлар үттем,
Галим була яздым,
Җырда яңгырый
Үткән юлларым.
Күп ялгыштым,
Хаклык тапмый уздым,
Тик качмады
Миннән дусларым.

Гашыйк иде безгә яшь сылулар,
Ә сөйгәнем миңа язмаган...
Юк, нигә соң көеп-сызланулар —
Бәхетем мине читләп узмаган.

Өч хәтәрне үттем,
Балаларның
Төшләренә
Бу хәл кермәсен.
Теләкләрен
Әйтәм аналарның —
Без күргәнне
Яшьләр күрмәсен!

## ШАГЫЙРЬ

Сугышта шагыйрьләр ут йөзә,
Тормышта җиңәргә өйрәтә,
Дошманга яшендәй ук-сүзе,
Дусларның йөрәген эретә.

Тезләнми, сатылмый акчага,
Эзли ул авыр юл, көрәшне,
Шиңмәс гөл чәчә гел бакчага,
Яшерми — эзләсәң киңәшне.

Кешегә ышану аңарда,
Ул алга, гел алга ашкына.
Туган ул ил өчен янарга,
Йөрәге гомергә яшь кала.

Ил булса шагыйрьсез — мантымый,
Гашыйклар бер-берсен танымый.
Чагыла ил көче шагыйрьдә,
Барыр юл күренә шигырьдә.

Ул әзер җиһанны җигәргә,
Көч эзли үлемне җиңәргә,
Шатлана, җырлый ул яшьләрчә,
Ватаны ныгынса, яшәрсә.

Чигенми, юк качып йөргәне,
Бетмәс көч, шиңмәс дәрт үзендә,
Һәр дәвер, заманның зәвыгы
Күренә шагыйрьләр йөзендә.

## САБЫЙ ХАТЫ

*(Сөйгән булып башлыйлар,*
*Балаларын ташлыйлар.)*

Сагындым, әнкәем,
Кайда син?
Ник ташлап калдырдың улыңны?
Бүлешеп
Ятимең кайгысын,
Күрсәтче
Барасы юлымны.

Шаярмам,
Уен, җыр ят миңа,
Мин хәзер
Зур инде — җидедә.
Әллә соң
Үз балаң оятмы?
Кайда син?
Әйтми бит җиле дә.

Күрдем төш
Үткән төн таңында.
Син, әни,
Яшь әти,
Энем дә,
Кайткансыз,
Бергә без тагын да...
Их, булса
Шул көннәр
Өнемдә!..

## ҖЫРЛАР ӘЙТӘ

Язын таллык-әрәмәдә
Сандугач сайрый,
Үткән яшьлекне яңартып
Таныш моң яңгырый.

Кайтчы, яшьлегем,
Тик берәр айга,
Әйтче, яшерми:
Бәхетем кайда?

Җырлар әйтә: үзем сөйдем,
Үзем яшердем,
Еллар үтә, юкны көттем,
Узды яшьлегем.

Кайтчы, яшьлегем,
Берничә көнгә,
Каршыңа чыгам,
Бирмәм беркемгә.

Җил-давылда баш имәдем
Өметне өзеп,
Кире кайтсаң, очар идем
Кошларны узып...

Кайт тик минутка,
Яңадан яшик?!
— Көтмә, онытма, —
Дип узды яшьлек.

## САКАТ ТАУЛАРЫНДА

Җырлыйк әле тагын бер таянып,
Зифа буйлы Бүә талына.
Искә алыйк, арып, чак тын алып,
Менүләрне Сакат тавына.

Баллы монда юкә урманнары,
Наратлар төз, ярда зиреклек.
Тонык Бүә, яшел болыннары,
Шомырт, балан, җыйсаң — җиләклек.

Сакат тауларыннан якын гына,
Үсеп килә яшь-яшь Яңавыл,
Өмет белән күңел дулкынлана,
Бәхет эзләп алда яна ул.

Искә төшә монда яшь чакларым,
Кем онытыр чибәр күлләрне?
Күңел түрләрендә гел саклармын
Гүзәл чакны, үткән көннәрне...

Гомер буе йөк күтәргән җилкә
Сораса да арып, бераз ял,
Без гел сафта, мөлкәт очмас җилгә,
Табар халкым тиздән дөрес юл.



РӘФИС МӨХӘММӘТДИНОВ

## ЯЗМЫШЛАР ТҮГЕЛ УЕН

Яралы кош килеп кунды,
Кан тама ярасыннан.
Канатлы да бит, барыбер
Сызлана минем сыман.

Ярдәм кулларымны сузып,
Үрелдем, җитми буем.
Аңладым, бүген аңладым,
Язмышлар түгел уен.

## БОЛЫНДА

Казлар чыкты, бәпкәләре
Яшел үлән чүпләп йөри.
Чәлдерергә бәпкәләрен,
Бер төйлегән читләп йөри.

Ата каз, һай, сизгер бит ул,
Төйлегәнне куып китте.
Башка яктан икенчесе
Ни арада килеп җитте.

Аналары бирәме соң,
Җыеп алды канатына.
Ә мин уйлыйм ятимнәрне,
Йөрәгемнән кан атыла.

## ТАШ БӘГЫРЬ

Ана газиз улын көтеп,
Ничәмә таңнар ата.
Шахтер егет — аның улы,
Күп еллар ташлар вата.

Ялгыз ана яшен түгеп,
Йота соңгы ашларын.
Ник ватмады соң ул егет
Бәгырькәе ташларын?!

## ЮК, КИТӘСЕМ КИЛМИ!

Бәхетне шул Ходай тигез бүлми,
Биргәненә — бирә тау өеп.
Сәламәтлек булса, бүген сиңа
Утырыр идем әллә баш иеп?!

Давылларда торып калганмын шул,
Язмышыма яшим буйсынып.
Кирәк түгел миңа синең байлык,
Кызыктырмый синең буй-сының.

Тик, туганым, сиңа бер үтенеч:
Очар канатымны каерма.
Син җанымны аер минем тәннән,
Туган җирдән мине аерма!

## КАЙТУ

Челтәрләнгән инде кар катламы,
Яз кояшы карый дөньяга.
Гөрләвекләр ага, елга таша,
Кошлар кайта туган ояга.

Канатлылар — нинди бәхетлеләр —
Туган җирдә оя яңарта!
Шатлыклары тышка бәреп чыгып,
Тирә-юньгә моңын яңгырата.

Бер бабай да кайткан туган якка,
Түбән иеп йөри башкаен.
Кире борып булса гомер угын,
Салыр иде нигез ташкаен!..

## САГЫНУ

Кичке моңнар агыла авылымда,
Яшьләр йөри гармун уйнатып.
Тәрәз читләреннән качып кына,
Бер әбекәй кала күз атып.

Сагынадыр ул да яшь чакларын,
Күзләп кала авыл яшьләрен.
Урамнарда моң агылган чакта
Күзләрендә күрәм яшьләрен!

## КЫШ ҺӘМ ЧӘЧӘКЛӘР

Зәңгәр күкләргә карадым —
Ап-ак болытлар ага.
Кышлар җиткән, гөлләр туңган,
Сабакларын җил кага.

Энҗе булып кар сибелә,
Күңел гөлем чәчәктә!
Гөлләрем туңмас, син ташлап
Китмәсәң киләчәктә!

## ҮЗ ГӨЛЕМ

Көннәр буе болыннарда
Үз гөлемне эзләдем.
Болында гөлләр күп булды,
Тик аларны өзмәдем.

Эзли торгач, үз гөлемне
Табып алдым кулыма.
Өзә күрмә ят гөлләрне,
Нур сипсә дә юлыңа!

* * *

Тәрәзәмә таш аталар,
Ваталар пыяласын.
Беләләр останың килеп,
Яңадан куяласын.

Күңелемә таш аталар,
Беләләр уаласын.
Нинди оста куяр икән
Күңелем пыяласын?!

## КӨЗГЕ ТАҢДА

Көз — көз инде, иманнар дә
Сарыларга сарыла.
Көз сарысы сагыш булып,
Күңелләргә кагыла.

Ялгызларга бигрәк авыр
Ак томанлы таңнарда.
Көзге җилләр, кагылмагыз,
Яз бар әле җаннарда!

## САНИЯ ВӘЛИУЛЛИНА



### ЧИШМӘ

Авыл таңын
Сәламләгән чишмә,
Агып килә
Таудан, еракган.
Көмештәй саф
Энже тамчылары
Тулып ага ике улактан.

Куш кулларга алып
Су эчкәннәр,
Рәхәтләнеп тыңлап агышын.
Ярларына утырып
Тыңлаганнар
Көмеш суларының тавышын.

Чишмә сукмагында әтием бит
Әниемне күреп танышкан.
Чишмә суы
Саф мәхәббәт биргән,
Яшь йөрәкләр
Сөеп кавышкан.

Чишмә аккан
Еллар исәпләми,
Һаман ага
Ярсып, uралып.

Сукмагыннан
Яшьләр атлаганнар
Саф суыннан яңа көч алып.

Бир син, чишмә,
Минем әниемә
Шушы суның
Тик бер тамчысын.
Алып кайтыйм аңа
Көчтәнәчкә
Яшьлегенең тәүге чаткысын.

## НИЧЕК ХӘЛЕГЕЗ?

Туган якны
Өзелеп сагынганда
Кайтып урыйм шулай авылга.
Яшьлек сукмагымнан
Атлап үтәм,
Һич карамыйм җилгә, давылга.

Йөргән юллар,
Таныш урамнарым,
Авылдашлар, ничек хәлегез?
Туган ягым,
Саф һавалы авылым,
Өзелеп сагынып
Кайттык сине без.

Челтерәп аккан елга,
Тау чишмәсе,
Суларыгыз һаман тәмлеме?
Җәйге кичтә җырлап
Үткән аланлыклар
Яшьлектәге кебек ямьлеме?

Түбән очта
Яңа урам күрәм,
Авыл үсә икән тагын да.
Ул-кызларың хәзер
Ташлап китми,
Язмыш үзе бәйли авылга.

Кайтып күрдем,
Урамнарда йөрдем,
Авылдашлар, белдем хәлегез.
Туган ягым, саф һавалы авылым,
Сагынырбыз сине әле без...

## КОРЫЧ БУЫНГА

*Сыйныф җитәкчем Саймә Хөсәен кызы Чанышевага*

Бала чагың авыр чорда үткән —
Кайгы баскан чакта илемне.
Ач, ялангач, җәяү ерак йөреп
Түләп укып алдың белемне.

Сезнең буын — корыч буын, диләр,
Корычтай шул, әйе, түземле.
Бик күп төрле сынауларны үттең,
Исән калдың, җиңдең үлемне.

Мәктәп сиңа изге урын булды,
Тормыш юлын үттең шушында.
Шау-гөр килеп укучылар белән,
Уйламадың үзең турында.

Яшь буынны тәрбияләү эше
Авыр, әмма лаек мактауга:
Рәхмәт сиңа изге эшең өчен,
Күпме белгеч бирдең Ватанга!

## МЕДСЕСТРА АПАГА

*Бөек Ватан сугышы ветераны Зоя апа Хәбибуллинага багышлыйм*

Зәп-зәңгәр күзләре,
Ягымлы йөзләре,
Күпләрнең күңелен
Күтәрде сүзләре.

Кечкенә куллары
Фронтта күпләрнең
Бәйләгән ярасын
Һәм тапкан дәвасын.

Сырланган йөзләре
Күп сагыш сөйлиләр.
Орден һәм медальләр
Күкрәген бизиләр.

Зур сугыш еллары
Төш булып калалар.
Шанлы юл үттегез,
Дан сезгә, апалар!

## КЕМ ТИГӘН?

Язын матур
Үсеп килгән гөлем,
Җәй уртасы җиткәч
Ник шиңгән?
Таптаганнар үзен,
Нинди хәлсезләнгән...
Матуркаем, сиңа
Кем тигән?

Гөлбакчаны бизәп
Утырган гөл,
Башың имә,
Сиңа су сибәм.
Җәй атмаса чәчкәң,
Көзен атар өчен
Явызларның кулын тидермәм!

ТАҺИР ШӘРИПОВ



## ТУГАН ЯГЫМ

Шаулап үтте Яңавылда
Балалык, яшьлек чагым.
Кая барсам — күз алдымда
Яңавыл — туган ягым.
Эшкә дәртлеләр кешеләр,
Йөриләр җырлап, биеп,
Каршылый кырда игеннәр
Тук башакларын иеп.
Күтәрелә таш йортлары,
Көн саен сәлам биреп.
Тора нефть вышкалары
Кырларда күкрәк киереп.
Күрсәгез, исегез китәр,
Булмаса барганыгыз.
Балкып тора тирә-яклар,
Нур сибә Карманыбыз.
Су сорасаң, сөт бирәләр
Авылларда кызлары.
Мәхәббәткә дару, диләр,
Шул кызларның үзләре.
Җитмеш авыруга шифа
Кымыз дигән сыебыз.
Килегез кунак булырга —
Ямьле Бүә буебыз.

## ЧӘЧӘКЛӘР БҮЛӘК ИТӘМ

Тәрәзәдән яз кояшы карый,
Хуш исләрен сибә сиреньнәр.
Их, күрәсе иде урамнарны!
...Тора алмыйм яткан җиремнән.
Тормыш ямен кабат күрмәм, дидем,
Шомга калдым, сызылып таң атты...
Ак халатлы, уңган доктор миндә
Яшәү өметләре уятты:
— Син яшәрсең, һич кайгырма! — диде,
Кара чәчләремнән сыйпады.
Дарулармы, әллә җылы сүзләр
Авыруыма булды шифалы?
Шатлыгымнан күңел канатлана:
Хәзер бастым хезмәт постына.
Болыннарга чыктым, чәчәк җыйдым,
Бүләк итәм доктор дустыма.

## ОТЧЕТ

Совхоз үзәгендә шау-шу:
Кычкыралар, сызгыралар.
Конторага җыеп алып,
Активларны кыздыралар.
Бригадирлар атта чаба,
«Матай» белән куышалар.
Очраган бер азаматтан
Сорау алып кыешалар.
Бухгалтерлар карамыйлар
Уңнарына, сулларына.
Йөгерәләр бүлмә саен,
Кәгазь тотып кулларына.
Зоотехник отчет төзи,
Үзе шыбыр тиргә баткан, —
Телефонга чакыралар
Ашыктырып төрле яктан.
Мал-туарлар бигрәк ябык,
Булмый һич тә иткә биреп.
Кабартыр иде шуларны
Хәлдән килсә, бер тын өреп.
Бүлекчәләргә үзәктән
Катгый әмер китеп тора.
Управляющийлар фермада
Сөт саудырып, биеп тора.

Экономист кабалана —
Бер яза да тагын җуя.
Вакыты юк — укып тормый,
Кәгазьләргә ул кул куя.
Агроном да зыр әйләнә
Өстәленең тирәсендә,
Колагына кургаш куйган —
Ишетми ул әрләсәң дә.
Директор тәмам ярсыган,
Тик чыдавын гына чыда.
Алды белән кергән кеше
Арты белән килеп чыга.
Берәү сорый:
— Пожармы әллә,
Каралтымы янып киткән?
— Юк, янмаган, туганкаем,
Квартальный отчет җиткән!

## ХӨРМӘТУЛЛА

Каерылып иген унса,
Амбарлар да тулган булса, —
Их, яшәве күңелле соң!
«Эш — ул бездән тормый», — дигән,
Бөгелеп-сыгылып сүзен биргән
Хөрмәтулла түгелме соң?
Каерылып иген уңды,
Җыеп алыр көннәр туды, —
Их, эшләве күңелле соң!
Качып-посып печән чапкан,
Күләгәдә сузылып яткан
Хөрмәтулла түгелме соң?

## САЛИХ АБЗЫЙ

Уйнап-көлеп үтте яшьлек чаклар,
Тормыш дулкынына күмелде,
Шул елларда куллар беренче кат
Рюмкаларга табан үрелде.
Кияү булгач, үзе килеп керде
Авызыма майлы калҗалар.
Бокалларны күккә күтәргәндә,
Биеп торды балдыз, баҗалар...

Әле ял көн, әле бәйрәм, диеп,
Дус-ишләрем тынгы бирмәде.
Алар белән хәмер чөмергәндә,
Акыл, җуләр, тыя белмәде.
Кырык эшем кырык җирдә булды,
Кырыгы да ятты таралып.
Ишетелде кырык көнгә соңлап
Эш буенча һәрбер яңалык.
Озак йөргәләдем соңга калып,
Ашаганны тәнгә сеңдереп.
Тупсаларда каршылады хатын,
Авызымнан тынны өрдереп.
Еллар үтте. Акылландым бугай,
Тәүбә иттем шәраб затыннан.
Усал сүзләр түгел, елга сыман
Җылы сүзләр ага хатыннан.
Кырык эшкә кырык илһам килә,
Чат ябышам һәрбер яңага.
Әллә, димен, кире кайта микән
Үтеп киткән яшьлек замана?

## «МУЛЛЫК» СЕРЕ

Берәү килә «Москвич»та,
Машинасы өр-яңа,
Бишекле мотоциклда
Улы озатып бара.

Гадәттәгечә, урамда
Җыелган икән халык, —
Карап калдылар боларга
Шаккатып, хәйран калып:

— Магазинга кереп китте,
Берәр нәрсә аладыр.
— Төзелеш күп, инженердыр,
Берәр бина саладыр.

— Гадиләрдән түгелдер бу,
Галимнәр затыннандыр.
Фән эше белән мавыгып
Монда ята торгандыр.

— Әллә Уфадан жалоба
Тикшерергә килгәнме?

— Әйе, әллә торгашларның
Этлекләрен сизгәнме?

— Юкка баш ватасыз, — диде
Шунда арадан берсе, —
Бу бит безнең авылныкы,
Колхозда тегермәнче.

Җайлап кына эшли белә,
Тими җил, яңгыр-мазар.
«Муллыгы»ның сере ачык:
Амбар — тегермән — базар!

ЯХЪЯ ЙОСЫПОВ



## ҺӘЙКӘЛЛӘРДӘН АВАЗ САЛАЛАР

Минем дуслар — коралдашларым
Тынычлыкның кадерен беләләр:
Заводларда эштә йөзәләр,
Киң кырларда иген игәләр.

Минем дуслар — коралдашларның
Җиңүчеләр дигән даны бар.
Шуны хаклап күкрәкләрендә
Балкый медальләр һәм орденнар.

Кабат сугыш күрмәсеннәр диеп,
Җир йөзендә барлык халыклар,
Минем дуслар — коралдашларым
Узды күпме авыр походлар.

Йөрәкләргә әле һаман да
Тынгы бирми алган яралар.
Минем дуслар — коралдашларым
Һәйкәлләрдән аваз салалар:

— Ирек куймагыз сез сугышка,
Нык торыгыз, йомшак булмагыз,
Чәчәк кебек чакта өзелгән
Безнең гомерләрне уйлагыз!

## ҖИҢҮ ТАҢЫ

Кояш белән бүген Җиңү таңы
Шатлык хисе чәчә дөньяга,
Минем илем, минем батыр халкым,
Җиңелмәслек көчле булганга.

Сугыш бетте,
Дөнья тынып калды,
Яз җилләре исте кырларда,
Сандугачлар кайтты бакчаларга
Җиңү таңын мактап җырларга.

Җиңеп кайттык
Авыр сынау үтеп,
Җиңү байракларын балкытып,
Туган илем, җирләп фашизмны,
Мәңге бетмәс тиңсез дан тотты.

Аналарның
Күз яшьләре кипкән,
Җимерекләр инде төзәлгән,
Барлык кайгы онытылган кебек,
Йөрәк сагышына күмелгән.

Сугыш беткән,
Бик күп еллар үткән,
Җуелганнар хәсрәт юллары.
Хәтерләрдә һаман саклыналар
Һәлак булган ил батырлары.

Ил өстенә
Киләчәктә тагын
Давыл болытлары килмәсен,
Зәңгәр күккә дошман козгыннары
Үрелмәсен, мәңге менмәсен.

Һавалар саф,
Күк сөремсез булсын,
Нурлы кояш көлсен илемдә,
Тик тынычлык, тик иминлек кенә
Чәчәк атсын минем җиремдә.

## БӘЙРӘМ КИЛӘ

Яз ташкыны белән бәйрәм килә
Чәчәкләрнең исен аңкытып,
Бәйрәм килә Җиңү даны белән,
Ал байрагын горур балкытып.

Бәйрәм килә, гөрләп бәйрәм килә,
Яз ярына сыймый ашкынып.
Сандугачлар сөенеп сайрый бүген,
Уртаклаша Җиңү шатлыгын.

## КҮЦЕЛЛӘРДӘ МӘҢГЕ САКЛАНА

Көзге җилләр саргылт үләннәрнең
Әкрен генә сыйпый башларын,
Бәдрәштәге ялгыз бер кабергә,
Уйга бирелеп, күзем ташладым...
Әхмәдулла атлы батыр булган,
Һәрчак үткен тоткан кылычын,
Күп алышта аның батырлыгы
Данга күмгән сугыш барышын.
Разведкада оста «аучы» булган,
Алып кайткан тере «тел»ләр дә,
Ватан өчен туган егет, диеп,
Мактап сөйләгәннәр кызлар да.
Илбасарлар серен белү өчен
Батыр киткән дошман тылына.
Аны шымчы байлар тотып биргән,
Асканнар нәкъ шушы урында.
Олылар һәм яшьләр, балалар да
Өзми эзне солдат каберенә,
Моңлы ядкәр булып герой даны
Күңелләрдә мәңге саклана.

## ДАН ТАРАТКАН

Диңгез кебек дулкынлана
Алтын бодай басуы,
Мул уңышка сокланганда
Арта йөрәк ярсуым.

Кыр корабы йөзгән кебек,
Тибрәлгән дулкыннарда,
Илемнең бетмәс байлыгы —
Тук алтын орлыкларда.

Корабның капитанындай,
Штурвалдагы егет.
Дан тараткан тирә-якка,
Күп батырларны җиңеп.

## УКЫТУЧЫ

Менә класс,
Иркен, якты, пөхтә.
Күпләр алар Туган илемдә!
Укый анда бихисап балалар:
Минем улым, синең энең дә.

Укытучы, яхшы бакчачыдай,
Бөтен гомерен бирә балага,
Кешелекнең акыл хәзинәсе
Сеңеп калсын, диеп, аңарда.

Күрәсеңме,
Укытучы, әнә,
Сулар бөрки гөлләр өстенә.
Бик тырышып салкын кыш буена
Язга яшь шытымнар үстерә.



ВЕНЕРА ҚАҺИРОВА

## БАР ДӨНЬЯНЫ ҚИЛӘ КОЧАСЫМ

Қайвакытта бик бисем килә,
Талпынасым килә, очасым,
Галәм киңлегеннән йөзеп кайтып,
Бар дөньяны килә кочасым.
Нидер җитми, нидер эшләнмәгән, —
Йөрәк дулый, ярсый, ашкына.
Су астында сарай салыр идем,
Булсам әгәр елга ташкыны.
Сихри көчләр миңа бирелмәгән,
Булдым бары адәм баласы.
Җир йөзендә, димәк, бардыр әле
Изгелекләр кылып каласым.

## ТУГАН ҖИРЕМ — БАШКОРТСТАН

Туган җирем — Башкортстан,
Туган телем — татар теле.
Туган җирем, туган телем
Минем өчен шундый изге.

Туган җирем — күңел гөлем,
Туган телем — балам теле.
Берегезне югалттыммы —
Бу дөньяда булмам төсле.

## ГАФУ ИТ СИН МИНЕ!

Мин бәхетле, дустым, әгәр күрсәм
Күзләреңдә чиксез елмаю.
Йөрәк әрни, өзгәләнә һәрчак,
Йөзләреңдә күрсәм моңаю.
Изге чишмәләрнең бирер идем
Иң шифалы серле тамчысын.
Нигә шулай түпәли соң кайчак
Язмышларның усал камчысы?
Өзгәләнә йөрәк, онытылмый
Язмыштагы тирән ялгышым.
Юлыкмасын иде юлларыңа
Тәкъдирләрнең явыз каргышы.
Күрсәм иде йөзләреңдә һәрчак
Шатлык, бәхет һәм дә елмаю.
Бүләк итәм бары якын дуслык,
Янсын юл күрсәтеп маягы.
Авырлыклар әгәр очрый икән,
Ярдәм кулын сузып барырмын.
Мәңге дустың булып калырмын,
Синең язмышында янармын...
Гафу ит син мине, гафу ит!

## КИТ, ДИСЕҢМЕ?

Кит, дисеңме? Китәм, сау бул инде,
Узган гомерем сиңа атадым.
Күпме генә сулар сипсәм дә мин,
Гөлләрем һич чәчәк атмады.
Кит, дисеңме? Китәм, сау бул инде,
Бер хушлашкач, кире кайтмамын.
Китәм, әгәр син телисең икән
Таңнарыбыз бергә атмавын.
Кит, дисеңме? Китәм, сау бул инде,
Куеп китәм йөрәк җылысын.
Гөлем кала, яшьлек гомерем кала,
Бар шул әле әрнеп елыйсың...
Кит, дисеңме? Китәм...

## ИРТӘ БЕЛӘН БАКЧАЛАРДА

Иртә белән бакчаларга
Чыгып карап торам да,
Җаннарыма нур ургыла
Таңда, кояш нурында.
Сандугачлар сайраганын
Тынып, тыңлап торам да,
Йөрәгемә моң ургыла,
Көчләр арта шул моңнан.
Ә бакчамда — алсу гөлләр,
Аларда — чык тамчысы,
Маңгайларның сырын җуя,
Табын юа язмышның.
И, табигать, гүзәл дөнья,
Синсез булыр идемме?
Көч бирмәсәң, җиңмәс идем
Синсез кайгы-иделне.

## БЕЗНЕҢ ӘНКӘЙ

Туган көнең котлап, бирик микән
Дөньядагы барлык гөлләрне?
Тик барыбер кадерлерәк безгә
Син өләшкән күңел гөлләре.
Изгелектән бәйләп бер гөлләмә,
Йөрәк җылысын да кушаек.
Бар сафлыктан тусын яңа бер җыр,
Һәм әнкәйгә атап җырлаек.
Буласың син кайвакытта боек,
Кайвакытта яшьнәп янасың.
Кызларыңны, улың, киленеңне
Балам, диеп озатып каласың.
Бары да сыя синә. Шатлыгы да,
Кайгысы да кайта кайчакта.
Бар арулар беткән кебек була
Яннарыңа синең кайтсак та.
Нәрсә бирик, нәрсә бүләк итик,
Ни әйтсәк тә, сүзләр аз, беләм.
Озын гомер синә, мәңге яшә,
Яшәрә күр һәрчак яз белән.

## ФӘРЕШТӘЛӘР ДӘВАСЫ

Кайгы-авырлыкка буйсынмадым,
Таптап уздым, җиңеп барысын.
Батырлар бит ярасыз булмыйлар,
Сала бара язмыш ярасын.
Үткәннәргә кире кайтып булмый,
Тормыш ярасында — язмышым.
Балаларым ялгышмасын өчен
Изге сукмак килә саласым.
Иңнәреңдә ак фәрештә булып,
Юл күрсәтеп килә барасым.
Язмыштагы барлык ялгышларны
Яңгыр булып килә юасым.
Изге теләк, изге ниятләрем —
Бәлки фәрештәләр дәвасы.

* * *

Табигатьтән изгеләр дә туа,
Яманнар да шулай туалар.
Кайбер кеше үзе дәва сиңа,
Ә кемнәрдер чиргә салалар.
Усаллык һәм гаделсезлек аша,
Байлык, диеп, юллар салалар.
Бу — мин, диеп, таптый, талый торгач,
Кипкән чәчәкләрдәй сулалар.
Аңлатасы иде шундыйларга
Башка дөньяның да барлыгын.
Саф мәхәббәт һәм дә матур яшәү
Изгелекләр аша туганын.
Алар күңелендә гөлләр кипкән,
Сары яфрак, күзләр — томанда.
Андыйларга акыл соңлап килә,
Аңлый бары гомер узганда.
Үкенүнең кирәге дә калмый
Йөрәккәең яфрак койганда.



СӘГЫЙТЬ НУРМӨХӘММӘТОВ

## ҖӘЙГЕ ТЫН КИЧЛӘРДӘ

Җәйге тын кичләрдә
Агыла сихри моңнар.
Әллә җырлый күңел,
Әллә чыңлый кыллар,
Әйтерсең, арфада
Уйный сылу кызлар.

Яңгырый ул моңнар
Елга буйларыннан,
Бөдрә таллыклардан,
Яшел камышлардан...
Гашыйкларның хисен
Көмдер көйгә салган.

Селкенә яфраклар,
Тибрәлә камышлар,
Әллә йомшак җилдән,
Әллә сихри көйдән,
Әллә тын ярларга
Кавышырга килгән
Бәхетле парларның
Кайнар сулышыннан.

## ЯШЬЛЕГЕМ ТАҢЫ

*(Җыр)*

Күмелә нурларга авылым таңнарда,
Елга буйларында сандугач моңлана.
Сандугач сайравын онытылып тыңладым,
Әйләнеп кайткандай яшьлегем таңына.
    Кушымта:
    Төшәләр исләргә, төшәләр яшь чаклар,
    Яналар ярларда, яналар учаклар.

Гөнаһсыз яшьлегем, кайда син, кайда соң
Өзелеп сөелгән бәхетле чакларым?
Бергәләп аттырган былбыллы таңнарны
Күңелем түрендә кадерләп сакладым.
    Кушымта:
    Төшәләр исләргә, төшәләр шул чаклар,
    Яналар ярларда, яналар учаклар.

## ЯЛГЫЗ КАЛДЫМ

Кагылмадың миңа, тик карадың,
Керфекләрең сирпеп, елмаеп.
Тиз-тиз генә китеп бардың аннан,
Ә мин ялгыз калдым моңаеп.

Нинди уйлар белән яшәдең син
Шул минутта, шушы мизгелдә?
Ә мин исә өр-яңа хисләрнең
Уянганын тойдым күңелдә.

* * *

Аланнарда печән чабам,
Колачларны каерып.
Кошлар моңлана тирәктә,
Китүләргә кайгырып.

Тирбәләләр талгын җилдә
Яфраклар агачларда.
Туган якның гүзәллеге
Онытылмый беркайчан да.

Китмәгез, кошлар, китмәгез,
Үкенерсез берзаман.
Туган җирләрне сагынып,
Омтылырсыз сез һаман.

## САНДУГАЧ

— Күңелләрне җилкендереп,
Күмеп моң-сагышларга,
Ни дип сайрыйсың, сандугач,
Җәйге матур таңнарда?
— Ерак-ерак илләр гизәм,
Сагынып туган якларны,
Елга буйларында үскән
Зирекләрне, талларны.
Туганнарым, былбылларым
Беларусь илләрендә.
Ватан өчен башын салган
Егетләр җирләрендә.
Орлов, Курск якларында,
Оренбур даласында,
Бохара бакчаларында,
Илен мактый барсы да.
Гүзәл минем туган илем —
Илһамым чыганагы.
Җырламый ничек түзәрсең
Аның якты таңнарын.
Кошларның мин иң даһие —
Танылдым моңым белән.
Кеше дигән олы җанны
Юатам җырым белән.

## ӘГӘР ЧЫКСАМ БАСУ СУКМАГЫНА

Атлаганда басу сукмагыннан
Бала чагым төшә исемә,
Әни белән урак урган чаклар,
Исереп яңа икмәк исенә.
Чыккан саен басу сукмагына
Бытбылдыклар дәшә ерактан.
Иген дулкыннары кочагында
Йөзгән кебек булам колачлап.

Әллә ниләр була күңелемә
Күз төшерсәм урман ягына.
Басу читендәге бер карт каен
Чакыра кебек мине янына.
Толымнары җиргә тиеп тора,
Җыерчыклар баскан ак йөзен.
Тирәсендә, сылу кызлар кебек,
Яшь каеннар киткән тезелеп.
Сабый чакларымда тирбәткән ул
Ботагында назлап мине дә.
Төпләрендә үскән җиләк белән
Сыйланганым истә бүген дә.
Ерак еллар алга килеп баса,
Хатирәләр китә яңарып.
Михнәт диңгезендә күп йөздек шул,
Яшәдек ул чакта кыл ярып.
Каен толымнарын бүлә-бүлә,
Әни чыгар сыман каршыма.
Ай урагын тоткан кулын изәп,
Чакырырдай мине ашына.

## БӘХЕТ ТУРЫНДА

Ни зурлыкта бәхет, күпме саны,
Җитәме ул барлык кешегә?
Нишләр идең, син бәхетле чакта
Дустың тирән кайгы кичерсә?

Кайгыларны була уртаклашып,
Мөмкин шатланырга бергәләп.
Кем бәхетен сиңа бүлеп бирсен,
Тормышны бит булмый бүлгәләп.

Яраттым бер мин дә, саф йөрәгем
Әверелде янып күмергә.
Ләкин булмады шул затлы маллар
Чәчәкләргә төреп бирергә.

«Була алмам, ахры, синең белән
Беркайчан да тулы бәхетле».
Шулай диеп, үзе дә сизмәстән,
Алып китте минем бәхетне.

## ҚЫРПАҚ ҚАР

*(С. Есениннан тәрҗемә)*

Атта барам. Кышкы тынлык.
Чыңлап куя дагалар.
Тик болында гаугa ясап,
Оча ала каргалар.

Гүя, кемдер сихерләгән,
Төш күреп йоклый урман.
Менә нарат. Ак косынка
Ябынып куйган сыман.

Иелгән карчыклар кебек,
Таякланган таякка.
Тукран тукый тук-тук итеп
Иң очында, ботакта.

Қар ява, җәя ак шәлен,
Қиңлек ярып, ат чаба.
Чиксез юлым тасма булып
Сузылган еракларга.

# ХИКӘЯЛӘР



ИНСУР ШӘНГӘРӘЕВ

## ХОДАЙ ХӨКЕМЕ

Кичә, кичке якта, Яңа күпер урамындагы унынчы санлы йортта зур фаҗига булган. Өч катлы йортның түбәсеннән калын боз катламы ишелеп төшеп, Зәкәрия исемле ирне басып үтергән. Яңалыкка сусаган тирә-як йортларда яшәүчеләр, «гөж» килеп, шаулашып, хәбәр сөйли.

Икенче көнне күршедә урнашкан унберенче санлы йортның ишек алдына да кич эштән кайтып килүче халык җыелды. Һәркемнең үз сүзен әйтәсе, мәрхүм белән булган вакыйгалар турында сөйлисе, аның хакында белгәннәрен башкалар белән уртаклашасы килә. Кемдер кайчандыр бергә табында утырган, кемдер бергә эшләгән, кемнеңдер улы аның кызы белән бер мәктәптә укый икән. Тик иң мөһиме, кешеләрне нык кызыксындырганы — аракы эчкән булганмы, юкмы? Бу сорау, билгеле, күбрәк хатын-кызга тынгылык бирми.

— Эчкән булганмыни соң?

— Эчкәндер, эчми әллә. Хәзер эчмәгән ир бармыни?!

— Юк, алай бик «төшереп» йөргәне сизелми иде.

— Бәлки эчкәндер дә. Кайбер акыллы ирләр, эчсә дә, кешегә күрсәтми. Безнекеләр кебек, урамда аунап ятып, кеше көлдерми.

— Өй алкашы, дисең инде? Бәлки саранлыктандыр? Безнекеләр генә ул, «дусларны» сыйлыйм дип, ыштанын салырга риза...

— Я, хатыннар, әллә нәрсә сөйләмәгез мәрхүм турында. Урыслар, әнә, мәрхүм турында яки яхшысын гына искә ал, яки бернәрсә дә сөйләмә, ди.

— Анысы шулай инде. Әле болай гына әйтүем. — Тик тагын үзе үк: — Нигә, дөрес түгелмени? Катылыкка каты иде инде. Бурычка кайчан гына акча сорап керсәң дә, белгәне «юк» булды...

— Әллә үчең бар идеме — кирегә сукалап тик торасың?

— Нинди үчем булсын ди? Бергә тапканым да, сатканым да булмады.

— Соң, шулай булгач, сиңа саран ни дә, юмарт ни...

— Урыны җәннәттә булсын, диген, ичмасам.

— Эчкән булган, ди шул. Алай күп түгел бугай. Хатыны Фания теге сатучы Зәбирәгә сөйләгән. «Нигәдер эч пошып тора, арытты да, хатын, китер әле саклап тоткан яртыңны», — дигәч, биргән идем. Бер рюмка гына салып эчте дә, аш ашады, чәй эчте. Аннан тәмәке тартырга дип, ишек алдына чыкты. Нәрсәдер «гөрст» иткәнгә, кешеләр кычкырышканга тәрәзәдән карасам, боз астыннан ике аягы гына күренеп тора. Йөрәгем ярылгандай булды. Их, ничек сизмәдем, нигә әйтмәдем, башка вакытта бәдрәфкә генә кереп тарта иде бит. Хәзер үкендең ни дә, үкенмәдең ни. Әҗәле алып чыккандыр инде», — дип елаган. Шулай сөйләп торды Зәбирә.

— Шулай инде. Әҗәлең җитсә, күркә таптап үтерер, ди.

— Әйткән идем бит, эчкән булгандыр, дип.

— Һи, ул явыз аракы кемнәрнең генә газиз башына җитми дә, кемнәрне үксез ятим калдырмый. Ходай күрсәтмәсен инде, безнекеләр дә эчә. Ут йотып өйдә ятасың, кайда, нәрсә эшләп йөри икән, кемнәр белән сугышты икән, кайда үтереп ташладылар икән, дип. Я, Ходай, үзең ярдәм бир бәндәләреңә...

Сүз әле бик озак шушы фаҗига тирәсендә әйләнде. Иң соңыннан чыгарылган «хөкем карары» кыска, ләкин каты булды: бу эчкечелек күпме өрлек кебек ирләрнең башына җитә. Менә тагын бер мисалы — күрше йорттагы бәхетсезлек очрагы.

Тик бер як читтә хатыннар гайбәтен сүзсез генә тыңлап утырган, бераз кызмача Зәки абзый гына үзалдына сөйләнеп куйды:

— Ярый, эчкән дә, ди. Тәмәке тартып түбә астында торган, ди. Өстенә бозлы кар ишелеп төшкән дә, үлгән, ди. Тик монда аракы белән үлем сәбәбе арасында нинди бәйләнеш бар, аңламыйм. Ир кеше үлсә, тоталар да, эчеп үлгәндер әле, диләр. Ходай хөкеме ул. Түбәне вакытында көрәргә...

Аның соңгы сүзләре өстән, түбәдән ишетелгән шатырдау, дөбердәү астында югалып калды. Түбәдән асылынып торган бозлыкарлы авыр масса ишелеп, бер-берсен уздырырга тырышып гәпләшеп торган хатын-кыз төркемен күз ачып йомганчы аяктан екты. Үзәк өзгеч кычкырулар гына ишетелеп калды. Тиздән өч-дүрт хатын-кызны бер-бер артлы килеп җиткән ашыгыч ярдәм машиналары алып китте.

Өченче көнне кич күрше уникенче санлы йортның подъезд төбенә монда яшәүчеләр җыелды. Кичә унберенче йортта хатыннар

белән булган хәтәр вакыйгага карата үз сүзеңне әйтми, белгәнеңбелән уртаклашмый, бераз гайбәт сатып алмый буламы соң инде...

Ә түбәдәге авыр карлы-бозлы масса, әкрен-әкрен генә шуышып, түбә кыегының читенә якынлаша иде...

## БЕР-БЕРСЕНӘ ОХШАГАН

Юлда йөргәндә, гадәттә, беренче тапкыр күргән кеше дә якын һәм үз булып китүчән. Синең аның белән танышуыңа әле бер сәгать тә үтмәгән, ә ул кешене инде берничә ел беләсең кебек. Һич тартынмый эч серләреңне сөйлисең, тормыш хәлләрен барлыйсың. Кешенең халәте юл йөргәндә кинәт үзгәрә, ул икенче кешегә әверелә. Галимнәргә киләчәктә кеше психологиясенә юл йөрүнең йогынтысын өйрәнү буенча күп эшлисе бар әле. Бу өлкә — күтәрелмәгән чирәм. Шаярта дип уйламагыз, минем болай җитди сүз сөйләгәнем дә юк иде әле.

Башкалага автобуста барганда бер гаилә әгъзалары белән урыннарыбыз янәшә туры килде. Үзләренең яше кырыкка якынлашып килсә дә, бер яшь ярымлык балалары да бар. Ире улын кулыннан да төшерми, аны төрлечә уйната, шаярта, анысы шаркылдап көлә, ачылыр-ачылмас теле белән нәрсәдер сөйләнә, аңлата, сораша, тәрәзәгә төртеп күрсәтә, автобус эчендәге пассажирларны күрсәтеп, нидер әйтергә тели. Әнисенең кулына бала тими дә. Аларга карап, читтән генә сокланып барам. Бәлки мәхәббәтләрен соңлап кына тапканнардыр, шуңа әле аеруча бәхетле вакытларыдыр, дип уйлыйм. Менә ямь өстенә ямь, бәхет өстенә бәхет булып, балалары да туган. Үзләре төскә артык матур булмаса да, уллары сабый гүзәллеге белән гүзәл. Тулырак кына ак йөз, яңа гына чыккан аслы-өсле дүртәр сөт теше энҗе кебек җемелди. Кием-салымы да бик чиста, пөхтә, аны өф итеп кенә торалар. Әлегә кыска йомшак кара чәчләре матур итеп таралган. Аңа сокланып карыйм. Бала миңа да елмаеп текәлә, кызыксынучан күзләре ялтырап китә. Мин дә аны үзем белгәнчә уйнатырга тырышам. Күчтәнәчкә дип алган шоколад кәнфитне сумкадан чыгарып кулына тоттыргач, «серләр» аеруча берегеп китте.

— Я, улым, нәрсә әйтергә кирәк абыйга? — дип атасы улына эндәшә. — Рәхмәт, дияргә кирәк, шулай бит?

— Әммәт! — дигән була тегесе.

Шулай безнең арада сүз иярә сүз чыгып китте. «Кунакка йөреп килергә булдыгызмы?» — дигән сорауга:

— Исәп шулайрак иде. Менә тормыш иптәшемнең әти-әнисенә улыбызны күрсәтеп килик әле, дибез.

— Улыгызның яше шактый күренә, әле һаман дәү әтиләренә күрсәтмәдегезме? — дип сорыйм аптырап.

— Шулайрак туры килде инде. Кайтып әйләнергә форсат ти-

мәде. Без илнең бер почмагында, алар икенчесендә яши. Үзләре килер иде, яшьләре шактый. Ә без салкын, кеше аягы сирәк баса торган якта акча сугабыз. — Әңгәмәдәшем көлеп куйды. Ул Привидение поселогын атагач, мин чыннан да шулай икәненә ышандым.

Шактый ара үткәч, автобус шоферы пассажирларны ял иттереп, аяк яздырып алырга туктады. Әңгәмәбез анда да туктамады. Галим исемле икән. Ул да минем тормыш хәлләре, кайда эшләвем, гаилә хәлем турында сорашты. Үземнең инде егерме ел гаиләле кеше булуым, ике бала үстерүебез турында әйттем.

— Ә сез яңа өйләнешкәнгә охшыйсыз. Әле һаман баллы аегызны үткәрмәгән кебек, — дим аны шаяртып.

— Һо, инде безнең бергә яши башлаганга уникенче елыбыз китте.

— Балалар ничәү соң, ишлеме?

— Ишле булмаган кайда! — дип яңгыратып көлеп җибәрде ул тигез тешләрен күрсәтеп. — Өч малай бар. Нәрсә эшләтергә, ничек карарга да белгән юк, баш катты инде.

— Ничә яшьтәләр соң? Үсмер балаларның хәзер характеры утыра башлаган чак, тәрбиягә авыр бирелә торганнардыр. Үз тәҗрибәмнән беләм. Яңа көн туган саен бүген нәрсә ватарлар, нәрсә җимерерләр, кеше нәрсә дип әйтер, мәктәптән кайсы укытучы чакыртыр инде, дип котым очып тора торган иде. Өлкәннәре ничә яшьтә соң?

Галим тагын бер тапкыр кычкырып көлде дә:

— Кадимгә — бер яшь тә җиде ай, Надимгә — бер яшь тә җиде ай, Сәлимгә — бер яшь тә җиде ай...

— Нәрсә, игезәкләрме?!

— Әйе, — диде ул һаман бәхетле елмаеп. — Хатын белән унике ел гомер кичердек. Балабыз булмады. Һәм кинәт менә шундый бәхет...

Шунда башыма уй килеп төште: әллә шаярта инде юлдашым? Өч игезәк, өч малай булгач, кайда соң калган... икесе? Бу сорау ничек тел очымнан ычкынганын сизми дә калдым.

— Ничек — кайда? Өйдә калдылар. Безгә бит балаларны карарга медсестра бирделәр, аннан, аларның барысын да бергә бу кадәр ерак арага ничек курыкмый алып чыгасың? Монда җылы булса да, безнең якларда буран уйный, салкын.

Шулай да мин бу хәлне берничек тә башыма сыйдыра алмадым. Ә дәү әтиләре калган ике оныгын күрә алмый бит. Һәм тиз генә күрә дә алмаячак. Әле менә ничә елга бер кайтырга туры килгән.

Тик ул миңа каршы төште:

— Юк, тукта әле, синең моңа аптырап калганыңа мин аптырыйм. Берсен күрде ни дә, өчесен бергә күрде ни... Алар бит барыбер бер-берсенә су тамчысы кебек охшаган. Әби белән бабай

түгел, үзем аермыйм әле аларны. Әнә, хатын ничек аерадыр... Әөч яшь бала белән Себердән, Ерак Көнчыгыштан Европага кайтуы ул сиңа пилмән ашау түгел.

Уйлап-уйлап тордым да, Галим белән килештем. Һәм аңа кушылып көлеп куйдым.

Менә шундый бәхетле гаилә белән танышырга туры килде миңа юлда. Һәм үкенмим. Бу хәлне кызык итеп, кемнәргә генә сөйләмәдем инде. Сезгә дә юлда йөргәндә тирә-ягыгызга күзегезне ачыбрак карарга киңәш итәм. Юлда аяклы мәзәкләр тулып ята ул. Кешегә сүз катарга гына иренмәгез, хәлен, тормышын сорашыгыз. Һәм сүз бәйләнә сүз китәр... берәр гыйбрәтле вакыйга ишетерсез. Килеп миңа сөйләсәгез, әбәзәтелни хикәя итеп чыгарам мин аны. Кулы белгән кешегә берни тормый ул...

КӘҮСӘРИЯ ШӘФЫЙКОВА



# ТУГАН КӨН

...Зәкинең колагына ниндидер тавышлар ишетелә: «Син аны гафу ит, балагыз хакына түзеп яшә!» — ди бер таныш булмаган тавыш. Икенчесе: «Син аны үтер, башыңнан күп көлде», — ди. Өченче тавыш килеп кушыла: «Әйе, үтер. Төрмәдән курыксаң, әнә бау, ул сине төрмәдән коткарыр, газапланып яшәгәнче каберга кер, анда тыныч!» — ди. Бер-бер артлы кайтаваз дулкынында кабатлана бу тавышлар. Зәки: «Нишләргә?» — дип, авырсулап, аракылы рюмкага үрелгән саен ишетә аларны. Баш шаулый, күз алдында томан, уйларның иге-чиге юк. Эчә Зәки, «Эчмә!» диюче юк. Роза үзе сыйлый ирен, җылы аш юк, ә аракы белән тозлы кыяр өстәлдә. Зәки, баш төзәтергә дип, аракы эзләп чыгып киткән иде, тапмады. Кайтуына — зәмзәм суы өстәлдә. Һәм шунда Розадан бәләкәй генә язма: «Әллә кайда йөрмә, туган көнең бит, сыйлан, мин хастаханәдә төнге дежурда!» Роза алдый, аның дежур төне түгел, Зәки моны бик яхшы белә. Әллә эчкән баш белән буталды микән? Юк, буталмый Зәки, Роза типтереп йөри. Бүген генә түгел бит инде, соңгы елларда арадагы салкынлык җанны өшетә. Роза үз теле белән әйтте, аңа Зәки белән яшәү кызык түгел, хатын башка ир белән үзен бәхетлерәк тоя. Ул ашыгыч ярдәм машинасы шоферы Хәмит белән түшәктә булган. Хәмит, ике балалы хатынын аерып, Розага өйләнәчәк. Роза Зәкигә барысын да үзе сөйләде, сөйләде дә: «Кит, ышандыңмы минем сүзгә? Көнләштереп әйтүем, Хәмит миңа пычагымамы! Син бар бит, Зәкикәем, син алтыным бар!» — дип кычкырып көлде дә ирен кочаклап үбеп алды. Зәки кайсы сүзгә ышанырга белмәде. Роза кайтмаган чакларда, эштәме-юкмы икәнен белешеп шалтыратты. Роза эштә булмады. «Сиңа әйтми генә авылга, әти белән әни янына кайттым ул төнне!» — дип акланыр юл эзләде. Юк, авылга да кайтмаган, бер иптәш хатынында булган, аракы исе аңкып тора иде иртән кайтып кергәндә. Ире белән бергә утырып эчми ул, чит-

тә эчәргә ярата. Зәки командировкада чакта бер абый килгән аларга, дүрт яшьлек Лилия әйтә. Сабый алдаша белми бит ул. Лилия алма ашаган, теге абый белән әнисе аракы эчкәннәр. Зәки инде ерак рейсларга йөрми, гаражда гына эшли, ә Роза һаман җай табып, төнлә кайтмый кала. Хастаханәдә дежурда булган һәм вәссәлам!

Зәки Розаны ярата. Гафу итте бит инде ул аны, ничә тапкыр гафу итәргә?! Зәки Мурманскида хезмәт итте. Көтәргә вәгъдә биреп калды Розасы. «Роза чәчәгем мине көтәр, өйләнешеп бик бәхетле яшәрбез!» — дип хыялланды егет. Ике ел вакытның минутларын санап, кайтыр көне җиткәнне көтте. Роза гына көтмәде аны. Зәки кайтуга бер егеттән алданып кияүгә чыккан иде. Зәки гафу итте. «Кыз бала бәхетсезлеккә очраган, кияүгә чыгуының бар сәбәбе шул, йөрәккәем, гафу ит аны!» — дип егет Роза белән очрашуга барды. Роза иреннән аерылган иде инде, өч кенә ай яшәделәр. Зәки яшәгән шәһәрчектә санитарка булып эшли иде. Зәки сизде, Розадан бик еш аракы исе килә, тик үзенә әйтмәде егет. «Өйләнешкәч эчмәс, әле минем алда үзен гаепле санап, борчылып эчәдер», — дип уйлады. Ялгышты шул, Зәки уйлаганча булмады. Роза эчкән килеш алданган, шул эчү аркасында ире белән аерылган, инде һаман тайгак юлдан баруын дәвам итә. Авырга калгач та, Зәкидән качып кына йота иде ул баш әйләндергеч утлы суны. Ярый әле кызлары гарип-фәлән булып тумады. Ходай саклагандыр. Зәки Розага кычкырып та эндәшми, кая ул кул күтәрү, рәнҗетү! Инде менә килеп җиттеләр, нишләргә дә белми Зәки. Онытылып торыр өчен, эчә башлады ул, юк, онытылып булмый, Розаның хыянәт юлында йөрүе чыгырдан чыгара Зәкине. Бик ярата да, хатынын тукмап ташлыйсы килеп, йодрыкларын төйни ул, иреннәрен чәйни.

Җәйге кич. Талгын җил агач яфракларын җилфердәтә, Зәкинең кара бөдрә чәчләренә кагыла. Инде ничә көн кырынмаган Зәки, өс-башы керләнгән, күлмәк сәдәфләре каптырылмаган, өзелеп беткән. Күтәрмәдә утыра, Розаны көтә. Ул исерек, бәйрәм итте бит, 26 яшь. Лилия кызы да юк бит янында, матур кызчытын сөяр иде, юаныр иде бераз. Розага булган ачу кимер иде бәлки. Лилия авылда, Роза аны әниләренә илтеп куйган.

Зәки тавышлар ишетә: «Роза ятлар куенында, көтмә син аны!» Зәки ярсый, чәчләрен йолкый. Күкрәге кыса, сулыш алуы авыр, һава җитми. «Розаны үтер!» Кем әйтә соң бу сүзләрне? Зәки тирәягына карана, юк бит, беркем дә юк. «Мин Розаны яратам, мин аны үтермим!» — ди Зәки, кемгә әйтә, үзе белми. Караңгы да төште, күк тулып йолдызлар кабынды. Ерак түгел, бакча башында таллыкта сандугачлар чутылдый. Матур кич, тик Зәкинең уйлары башка. Ул түзмәде, хастаханәгә юл тотты. Ак халатлылар аңа Розаның биредә юклыгын әйттеләр. Зәкинең тамырлары буйлап ярсу кан ага, тешләрен шыгырдатып, яшәгән йортларына та-

ба кызу-кызу атлый. Үз йортлары белән яшиләр алар, Зәкинең әти-әнисе сатып алып биргән иде. Бәхетле яши алмадылар. Зәки ишек алдына кермәде, урамдагы эскәмиягә утырды. Әлләниләр уйлады, мең үлде, мең терелде. «Асылынып кына үл инде, шундый пычрак хатын белән яшәмә. Кешеләр синнән көлә, бетсен бар газапларың, кит бу дөньядан. Дөньяга килеп бәхетле була алмадың, мәхәббәтең бәхетсез итте сине. Син Розасыз яши алмыйсың, тик ул башкалар белән бәхетле. Роза яшәсен, дисең икән, яшәсен, кызың әнисез калмасын, ә син кит, кит дөньядан!» Зәки колакларын куллары белән томалый, ә тавыш ишетелә. Кабаткабат әйтелә бу сүзләр. «Бау кайда икән?» Зәки урыныннан торып капкага килә, ишегалдында үскән бөдрә каенга карый. Каенның ботаклары аны гына көтәрердәй. Тик Зәки капканы ачып эчкә үтми, юк-юк, ул анда кермәячәк! Зәкине ниндидер көч урам буйлап алып китә, аның юлы әти-әнисе яшәгән биш катлы йортка таба бара.

— Нишләп йөрисең, балам? — дип курку белән каршылады аны әнисе. — Төнге сәгать өч!

— Яшәргә кайттым, әнкәй, анда мине үлем көтә, ә мин яшәргә телим! — Зәки әнисен кочаклап, үксеп җибәрде.

— Яшә, улым, син яшәргә тудың. Егерме алты ел элек дөньяга килдең син, мин сиңа яшәү бирдем. Туган көнең белән, улым!

Зәкия апа улын юатырга теләп, чәчләрен сыйпый, аркасыннан сөя. Үзенең иреннәре дерелди, күзләрендә яшь.

— Рәхмәт, әнкәй, рәхмәт яшәү биргәнең өчен. Мин нәкъ егерме алты ел элек гаиләгә бәхет, шатлык булып дөньяга килгәнмен. Кайгыга әйләнәсем килми, әнкәй. Синең, әткәйнең, туганнарның кайгы яшенә әйләнәсем килми. Уйлаган идем, әнкәй!

Зәки әти-әнисенә барын да сөйләде, аңа җиңелрәк булып калды.

— Улым, афәрин, мәхәббәтне үлем белән чикләргә ярамый! — диде Кәрим абзый, Зәкинең иңбашына җиңелчә сугып. — Гел шулай егет булып кал! Үлемгә кукиш күрсәтеп, яшибез әле, Алла боерса!

Ата, ана, ул таң атканчы сөйләштеләр, чәй кайнатып эчтеләр. Сөйләшеп сүзләре бетмәде. Зәки тәмам айныды, аек акыл белән фикер йөртте. Роза белән аерылырга карар итте ул. Роза ничек тели — шулай яшәсен, ул да үзенчә яшәр. Лилия үскәнче ярдәм итәр, сагынып күрергә барыр. Бала үсәр һәм барын да аңлар. Тормыш чынбарлыгы хыял кебек татлы гына түгел шул ул, ачы ул, әй, ачы! Башкаларның хатасын кабатламавына сөенде Зәки. Акылсыз адымга бармады, яшәүгә булган мәхәббәте саклады. Үлем үзе дә килми калмас, нигә аны ашыктырырга, кабат туып булмаячак бит! Розаны онyта алмас бәлки, бәлки мәңге гафу итмәс... Роза аны үлем турында уйларга мәҗбүр итте, ярый әле акыл өстенрәк булып чыкты. Зәкинең әрнүләренә дәва булырлык гөлләр бардыр әле дөньяда.



ҚАМИЛ ГӘРӘЕВ

## ШТАТТАН ҚЫСҚАРТТЫ

Беркөн кибеткә чыксам, исемлек буенча шикәр биреп яталар. Қилосы 750 сум. Нишлисең, пенсия акчамнан кесәм ярыйсы ук юкарса да, алдым. Хатын белән икебезгә ике кило тия икән әле. Хатыным: «Ирем миңа бигрәк игътибарлы, ярдәмчел», — дип әйтсен дисәем инде.

Шикәрне алып кайту белән, гадәте буенча, үлчәргә тотынды: «Посмотрим, — ди урысчалап. Үлчәү угына карагач, шаккатты әй: — Менә ичмасам экономия!» — дип кычкырып ук җибәрде. Ике килога 300 грамм җитми иде.

Экономия ясый белә шул безнең торгашлар.

Әле менә яңарак җылырак пальто тектерим дип, тегү мастерскоена барсам, тегүче товарымны аннан-моннан гына үлчәштереп карады да: «Җитми», — ди. «Җитәргә тиеш иде, яхшылабрак үлчәп карагыз әле», — дип каршы төшәргә маташкан идем, «Қибеттә урлаганнар ич!» — дип акырып җибәрмәсенме! Ча-ак чыгып йөгермичә калдым. «Хәзер кыскарту заманы, кыскарак тексәк, бәлки җитәр дә», — ди үзе тагын азрак йомшарып. Нишлисең бит, ризалаштым.

Бер атна үтүгә мастерскойга керсәм, тегеп элеп үк куйганнар, рәхмәт яугырлары. Пальтомны киеп карауга авып китә яздым. «Бәй-й-й, — дим. — Тәнемнең иң җаваплы урыннарын да капламый ич!» Ә миңа: «Савремун пальто шулай булырга тиеш. Заманнан артка калма, бабай», — диләр. Нихәл итәсең, пальто галәмәтен алып кайттым, ләкин кая инде аны киеп урамга чыгу! Экономиясе, кыскартуы шуның белән генә бетсә ярар иде, дип тынычланыйм гына дисәм, беркөнне хатын үземә: «Җитте! Мин сине штатымнан кыскартам! — дип ярсып кычкырып җибәрде. — Қая барсаң, шунда расход ясыйсың, үзең дә тәмам расходланып беткәнсең инде». Йокы урынымны аерым бүлмәгә җәя башлады. Нихәл итмәк кирәк... Үземнән күпкә яшь шул минем карчык. Менә бәла кайда!

## ЗАКУСКА

Ул көнне без, җәй буена бер тапкыр да Бүәгә бара алмавыбызны искә алып, Әдһәм кодам белән бергәләп балыкка барырга булган идек. Әйдә, көннәр буе базар почмагында сыра каравыллап интеккәнче, табигать почмагында баш тизрәк төзәлер.

Ни генә дисәң дә, пенсиядәге халык ялны культуралы итеп оештыра белә инде ул. Балык тоту өчен кирәк-яракларны, шул исәптән суалчанны да, кичтән үк әзерләп куярга булдык. Әдһәм кода ул яктан миннән тәҗрибәлерәк кеше.

— Балык ул суалчанның кызгылт төстәге симезләрен яратучан, ә андыйлар тиреслерәк урында, бакча артларында табыла,— ди.

Анысын да, кичтән үк, калай банкаларга тутырып, хәстәрләп куйдык. Су буена баргач, балык куркытып, суалчан эзләп йөрерлек булмасын, янәсе. Кичтән үк юнәтеп, теге биш мең биш йөзлекне дә берьюлы ике шешә итеп алып, сумкага урнаштыргач, тынычлап йокларга яттык. Юлыбыз уңай булыр сыман, икебез дә төне буе шул балык белән саташканбыз.

Иртән, минем тәҗрибәле кодам киңәше буенча, кибеткә дә кереп чыктык:

— Алай-болай балык эләкмәсә, берәр балык консервасы «эләксен». Бүген хакына карап торып булмый инде. Кичә генә пенсия алдык бит. Закускасыз да булмый, җәмәгать!

...Мондый бәхетле минутларны билгеләп үтмәү зур гөнаһ булыр, дип, барып җитү белән, учак-мазар да ягып тормыйча, дәртләнеп китеп, эш башлау өчен, сандугачлар моңы астында бер шешә акбашны бушатып та куйдык.

— Икенчесе белән уңышлы «ауны» юарбыз, — ди кодам.

Тик нишләптер без көткән балык кына эләгергә ашыкмый. Әллә нишләп бармак зурлык ташбаштан башка балык күренми. Кая булган соң әле бу данлы елганың ялтыр чабаклары? Биредә элегрәк бик шәп каба иде бит. Унлап ташбаш күтәреп кодам янына килсәм, ул «теге»нең төбенә төшеп җитә язган, үзе берничә ташбаш, ике алабуга да тотарга өлгергән. Миңа бик күңелсез булып китте бу минутларда. Көн дә бозылуга таба, сандугачлар да тынып калган, ә елга өстендә, караеп, нефть калдыклары йөзә... Мин шундый күңелсез уйларда басып торганда, кодам исерекләрдә генә була торган хырылдык тавышы белән:

— Кил, кода, сиңа да бар әле монда, — ди. Мин шешә төбен тәмамлап куйгач:

— Закуси, — дип калай консерваны алгарак этеп куя. Карасам, яртылаш бушаган... суалчан банкасы. Менә нчмасам закуска булган бу!



ӘМИР ФӘТЫЙХОВ

# ГАРӘФӘ ҖИЧ ТУГАН ӨМЕТ

Вәлинур Җирамов — безнең шәһәрнең ярыйсы гына абруйлы җитәкчесе. Әледән-әле яңа предприятие һәм оешмаларны «нығытырга» җибәрәләр аны.

Ләкин шушы уңган җитәкченең өлкән буын кешеләренә охшап бетмәгән бер ягы бар (дөресрәге, бар иде): үз телен начар белә, бер урыс кешесе булмаган җирдә дә русча тыкылдап теңкәләренә тия. Ел саен уздырыла торган отчет-сайлау җыелышларында да шулай булып килде. Ул докладын бер телдә ясый, ә фикер алышулар икенче телдә бара. Тәүге елларда аңа моның өчен әллә ни үпкәләмәделәр, русча укыган, бераз өйрәнсен әле, диделәр, ә менә соңга таба һәр авылда диярлек ризасызлык белдерә башладылар.

Һәм Вәлинур Җирамов, ниһаять, үзе әйтмешли, изменяться итәргә курс алды, җитешсезлеген төзәтергә, быелгы отчетын халык теләгәнчә ясарга һәм моны үз авылы Өчкаклыдан башларга булды. Иртән эшкә килеп, бөтен идарә төзегән докладны кулына алды да, аны шундук секретарена сузды:

— Ты у нас студент, языковед буласы кеше. Бөтен знаниеңне показать итеп, шуны переводлап бир. — Шулай диде ул, русча арасына әз-мәз татар сүзләре кыстыргалап. — Кичкә әзер булсын, — бу сиңа сынау, — дип тә өстәде.

Ә менә нәрсәгә икәнен искәртмәде. Кичен, тәрҗемә итеп, машинкада басылган текстны папкасына салды да графикта тәүге итеп билгеләнгән авылга юл тотты.

Ялтырап торган шомырт-кара «Волга» клуб янына килеп туктаганда аның ишегеннән пар бөркелеп тора иде инде: димәк, халык җыелган, аны гына көтәләр. Җитәкче ишектә күренүгә, зал дәррәү күтәрелеп кул чапты. Нишләргә белми утырган рәис шундук аңа сүз бирелүен белдерде. Төгәллекне яраткан Вәлинур «ә» дигәндә трибунада, «б» дигәндә докладын укуда булды.

— Җәмәгать! — дип башлады ул, бу юлы үзенең саф татар телендә отчет ясаячагын сиздерергә тырышып. Тәүге сүзен ул залга карап, кәгазенә иелмичә генә әйтте. Ә аннары иске гадәте буенча язылганны уку эшенә кереште:

— Альрафикун мөхтәрәм! Газиз вахтун! Нахакүнә каширун... мина... — Бу сүзләрнең татарча түгеллеген аңлар дәрәҗәдән ерак торган докладчы күкрәк киереп горур тавыш белән шул рәвешле укуын белде. Зал исә, үз араларында туп тибеп үскән егетнең әллә ниләр фәстеруенә төшенергә тырышудан битәр, беравык аның көр тавышына сокланып утырды. Өлкәнрәкләр докладчының һәр авазын хәтерләренә сеңдерергә теләп, аның кайдадыр электән дә ишетелгән нәрсәләр түгелме икәнлеген ачыклап утырдылар. Яшьләр, берни аңламыйча, иңбашларын сикерттеләр. Ә докладчы аның саен шәбәйде.

— Әлхәм эттихәт гамәлүн... әүвәл калиматуни... Өчкаклы кәрьятунинахакун, гамәлүн сто двадцать процент...

Отчет доклады урынына ни тыңлавын да белми аптырап утырган зал әллә нинди чит сүзләр арасында үз авылларының исемен ишетеп, кинәт таш ыргытудан дулкынланган тын су кебек чупылдап, калкынып куйды. Докладчы бу дулкынлануның акрын гына бөтен залга җәелә баруына, берәүләрнең пышын-пышын сүз алышуларына, икенчеләренең авыз каплап чырык-чырык көлешүенә һәм президиумдагыларның да һаман саен тынычлыгы бетә баруына да игътибар итмәскә тырышып, дөресрәге, шушы бетә барган тынычлыкны ничек тә кире кайтару нияте белән, башта абзац-абзац, аннары бит-бит калдырып, мәгънәлерәк сүзләр эзли башлады.

Берсен аннан, икенчесен моннан йолкып, «мөхтәрәм... тәхсин... нәсихәт... сурәтен, вал китабу» кебек әз булса да сүзгә охшашрак урыннарын укып китте. Ләкин бер кузгалган дулкынны тиз генә туктатырлык түгел иде. Тавышланулар аның саен көчәя генә барды.

Хәлнең яхшыга бармавын сизенгән докладчы президиумга борылып, аннан ярдәм көтте. Ләкин җыелышны алып順 баручыбыз кыңгыравын читкә этеп куеп, аның үзенә карап тора башлады.

Докладчы шунда, инде ярыйсы гына буталган кәгазьләрен югарыда калдырып, трибуна артында докладының русча нөсхәсен тапмакчы булып, папкасында актарынырга тотынды.

Кинәт урнашкан тынлыктан файдаланып, картлар үзара әңгәмә куертты.

— Кара әле, син нәрсә укыганын чамалый алдыңмы?

— Әллә тагын. «Тәһлил» дисәң, «Лә илаһи»дан башларга кирәк ие. «Әлхәм»гә охшап куя кебек.

— Син тагы... Мәетсез, «Ясин»сыз нинди «Тәһлил» дә, нинди «Әлхәм» ди ул тагын...

Картлар сөйләшүне тәмамларга өлгермәде, буш мөнбәр янә тулыланды һәм залга янә ят сүзләр сибелде:

— Әл әшшәдән вә сөбханикә...

Нәрсәдер көткән залны шунда, әйтерсең, шүрәле кытыклап үтте: яшьләр бер-берсенә авышып, эчләренә тотынды, картлар, җанланган саен җанлана барып, әлеге әңгәмәләрен куертты. Беренче булып залның нәкъ урта җирендә урнашып алган Нигъмәт карт телгә килде. Үзе ишеләргә күз йөгертеп, ул башта янәшәсендә утырган Закир картның кабыргасына нык кына төртеп алды:

— Әйткән идемме теге чакта, җүне килер, дип. Искечә белүче юк, мәхәллә тарала дип кайгырган идең. Күр менә...

Нигъмәт картның кояштай балкыган йөзендә нинди сер ятуын аңлау кыен түгел иде. «Я, нәрсә көтәсез, тотыныгыз эшкә!» — дия иде аның кыяфәте.

— Ашыгып, секретарем доклад урынына әллә нәрсә кыстырып җибәргән. — Үзенең уңайсыз хәлдә калуын аңлап, докладчы шулай дигән булды. Моңа арткы рәттән Тиктормас Гариф кычкырды:

— Ничава-ничава, бер дә әллә нәрсә түгел. Амин, диген дә, бүгенгә җитеп торыр.

Берьюлы яшьләрнең дә пырх-пырх көлешүен басарга теләп, инде Нигъмәт карт күтәрелде.

— Безгә бик тә аңлашылды доклад, иске авызга яңа аш, дигәндәй. Югыйсә, бөтенләй дә онытылып бара икән китап теле.

Боларны ул докладчыга карап, аны мактагандай әйтте. Аннары, янәдән үз тирәсендәге картларга күз йөртеп:

— Праулинжәнең эшенә бик әйбәт дигән уцинка бирәек тә, тавышка куйыйк. — Бу сүзләрен ул барысына да ишетелерлек итеп әйтте. Аннары тавышы беткәндәй, бер йөткереп алды:

— Коръән телен белүенә килгәндә, па-маему, мулла гына түгел, казыйга барырлык бу, — дип елмайды. Аның артыннан яше-карты аңларлык итеп әлеге Тиктормас ярып салды:

— Дөньяга үзебез хуҗаен диләр икән, рас, шулай булсын, сайлыйк та куйыйк.

Тиктормасның кеше көлдерү өчен әйткән бу сүзләрен кайсыдыр:

— А чту син думаешь, сайлауга килгәнбез икән, даваең, сайлыйбыз, — дип конкретлаштырып куйды, зал аңа үзенең «давае» белән кушылды.

Җыелышны алып баручы:

— Әле докладны тикшерү булмаган, кая ашыктырасыз? — дип кычкыручыларны тәртипкә китерергә маташып карады, ләкин залның шаркылдап көлешүләрдән, үзара сөйләшүләрдән туктарга исәбе юк иде. Һәм рәис, умартадай гөжләгән җыелышның ничек тә кортын басарга теләп:

— Ягез, я, аңлашылды, — дип ризалашырга мәҗбүр булды.
— Көн тәртибенең... Кем дә кем хөрмәтле Вәлинур Кирамовны...

Уеньш-чыныи бергә кушып, картлар арбасына утырып алган залда бөтенесен дә ишетерлек түгел иде, ләкин шул Тиктормас Гарифның әле бүген дә сөйләп йөрүенчә, моның кирәге дә юк иде. Кату алган эчләрне тотудан, колакка җитеп ерылган авызларны каплаудан арыган куллар куе урман булып күтәрелделәр дә кире төштеләр. Рәис: «Бертавыштан!» — дип йомгаклап куйды һәм идарәнең башка әгъзаларын күрсәтүне үтенде. Анда да шул Тиктормас калкып чыкты:

— Кемне дип, калганы билгеле инде аның. Менә Нигъмәт абзый — мөтәвәлли, тагын — Аптул. Каршы түгелсеңдер ич, кем, Аптул, читкә-мотка чабыла торган балтаңны куеп торырга?

— Булсын, булсын, мөфтигә барам дигән булып, «Уф-ти»гә акча туздырудан туктар ичмасам. Риза бул, әйдә, Аптул...

Үзенең доклад ясаудан җиңел котылуына сөенеп утырган Вәлинур Кирамов эшлекле сөйләшүнең булмый калуына да, эшне үтәүдән алда акча дауларга остарган Аптулны правление составына кертүләренә дә каршы килмәде. Килер иде, Нигъмәт карт белән Тиктормасның уенын-чынын бергә кушып әйткән сүзләреренең күбесен ул ишетмәде, ә ишеткәннәрен аңламады.

Җыелыш таралып, идарә әгъзалары үзләре калгач кына аңына килде ул.

— Нишлисез сез, товарищлар, шундый салидный собраниедә, да еще шундый заманда какой мулла сайлау, ди ул. Вот нашли! — дип картларны оялтмакчы булды. Ләкин соң иде инде, бик тә соң иде.

— Нинди булса, ярамаган тагын ураза үтеп барганын белмәгән Өчкаклы картларына. — Шулай дип кычкырды артына борылып, ишектән чыгып барган Тиктормас.

«Шатун» берләшмәсе рәисен Өчкаклыда мулла итеп сайлаулары турындагы хәбәр үзе клубтан чыкмас борын ук район үзәгенә, аннан башка авылларга таралып өлгерде. Иртәгәсен нинди генә оешманың ишеген ачмасын, һәркайда аны:

— Ә-ә, Өчкаклы хәзрәте! Әссәләмәгаләйкүм! Ягез, җәмәгать, дога кылып алыйк. Иншалла, собханалла. Амин, — дип бит сыйпап каршыладылар. Элекке секретаре, югары уку йортларының берсендә чит телләр өйрәнүче Җәүһәрия кызыксынучыларга:

— Ул вакытта аның авылда доклад итеп укыячагын кем белгән. Осталыгыңны күрсәт дигәч, күрсәттем инде, — дип аңлатты һәм җитәкчесен мулла итеп сайлатуга җиткергән «курс эшен» коллегаларына да күрсәтеп, тәүге «бишле»се белән мактанып йөрде.

Ләкин иң кызыгы Тиктормас Гариф сөйләве булыр. Гыйнвар кичендә булган җыелыш турында түкми-чәчми, вак-төягенә кадәр сөйләр-сөйләр дә, шулай очлап куяр:

— Искечә итеп әйтсәк, гарәфә кич булган хәл бу. Эш турында сөйләшә торган атчут-сайлау җыелышы, мин сезгә әйтер идем, онытылып беткән Коръәнне, оятыннан җимерелгән мәчетне соңгы тапкыр телгә алу гына булмады ул, яңасын салсак, мулласы да бар икән, дигән өмет уятты ул бездә.

# УЙМАК ХИКӘЯЛӘР



ДАНИС САДРИЕВ

## АЛТЫН ТУЙДАН СОҢ

Батырша абый белән Гөлфия апаның бергә яши башлауларының илле еллыгын — алтын туйларын балалары, туган-тумачалары, күрше-күләннәре, мәҗлес җыеп, киң билгеләделәр: озын гомер, тазалык-саулык, бәхетле картлык теләделәр.

Икенче көнне дә якын туганнары белән сөйләшеп сүзләре бетмәгән иде әле.

Шулчак Батырша абый урам буйлап югары очка баручы Шәмсия апаны шәйләп алды. Яшьлек мәхәббәтен, өйдәгеләргә сиздермәскә тырышып, тәрәзәдән-тәрәзәгә күчеп озатып калды. Бераздан, киенеп, тышка атлады. Кулына балта тотып, урам якка чыкты да, төзек капканың такталарына суккалап, кадакларын каккалап маташкан булды, ә күзләре бөрөзлексез югары оч урамын күзәтә иде.

Менә бераздан Шәмсия апа күренде. Ул якынайгач, Батырша абый аның каршысына ук чыгып басты. Нәрсә турында сөйләшкәннәрдер, анысын белмим, әмма яңадан өйгә кергәндә ул, гәүдәсе тураеп, үзе яшәреп калган сыман тоелды.

## АВЫР СОРАУ

Сәүдә апа туган авылына кунакка килгәч, ахирәте чәйгә дәште.

Менә алар, гөрләшеп, өстәл янында утыралар. Хәл-әхвәлләр турында сөйләшеп алгач, тынып калдылар. Шулчак Сәүдә апа, сүз югында сүз булсын, дип сорап куйды: «Улың кем исемле?» Ахирәте, күпме генә кашларын җыерып интекмәсен, улының исемен

исенә төшерә алмады. Җавап ала алмагач, Сәүдә апа үзе үк ярдәмгә килде: «Киленеңнән сора!»

Ахирәтенең йөзе яктырып китте. Йорт эшләре башкарып йөрүче килененә:

— Килен, ирең кем исемле? — диде.

Килене исә, бианасының соравына төшенеп җитмичә, аптырап калды. Шаяртмаганын аңлагач кына: «Фәез ич!» — диде.

Бу хәл барысының да күңелен күтәреп җибәрде, һәм алар, әллә үзләреннән, әллә картлыкның үзеннән рәхәтләнеп көләргә тотындылар.

## ДӨРЕС ШИКЛӘНҮ

Хәләл җефетем белән кайтып киләбез. Шулчак бичәсен култыклап барган танышым очрады. Исәнләшеп узып киткәч, хатыным кызыксынып сорап куйды:

— Әллә икенче бичәсеме?

Мин аның дөрес шикләнүенә аптырап калдым. Моны сизеп, ул янә өстәп куйды:

— Култыклашып баралар ич...

## ЯХШЫ СҮЗ ЯМАНЛЫГЫ

Бәйрәмнән соң эшкә килгәч, пошаманда басып торган дусымны күреп, хәленә кермәкче булдым.

— Бар да яхшы, — диде ул, — тик мәҗлестә... яратам, дигәнмен.

— Әйбәт сүз әйткәнсең!

— Юк шул.

— Хикмәт нәрсәдә соң?

— Бәла шунда, моны башка кеше хатынына ычкындырганмын, хәзер гафу үтенергә кирәк инде менә...

## ТИЗ ЭЧСӘҢ

Эштән кайтып керүгә, кечкенә кызым, зур батырлык эшләгән кебек, сөйләргә тотынды: «Мин әле чәйне тиз-тиз эчтем, ачысын сизми дә калдым диярлек. Син дә шулай ит, яме!»

Эй замана, барлы-юклы акчаңа алган тәм-томнар хәзер, элекке шикелле, өстәл өстендә тулып тормыйлар шул.

# ЖЫРЛАР



## ЯҢАВЫЛ

*Сәгыйть Нурмөхәммәтов сүзләре,*
*Әнис Шәймәрданов көе*




Яңавылның күкләрендә
Балкып яна йолдызлар.
Тапшырып ил сәламнәрен,
Җырлап уза поездлар.

Кушымта:

Яңавыл, Яңавыл —
Кичәге авыл,

Ә бүген, ә бүген
Яңа кала.
Эшчән, дәртле кыз-улларың
Киләчәккә юл сала.

Тирә-якта — киң басулар,
Шаулап үсә игеннәр.
Тамырлардан «кара алтын»
Агыла ил түренә.

Кушымта.

Сабыр гына ага Буә,
Туган җиргә ямь бирә.
Башкорт, мари, урыс, татар —
Бертугандай гомергә.

Кушымта.

Башкортстан — дуслык иле,
Киләчәгебез якты.
Данлы эшләр, матур җырлар
Бизәсен туган якны.

## ЯҢАВЫЛ — ЯНА УЛ!

*Гайнан Әмири сүзләре,* *Әнис Шәймәрданов көе*

Буә сукайлары таша,
Ярга кага дулкыннар.
Дулкыннар белән ярыша —
Шаулый алтын киң кырлар.

Кушымта:

Яңавыл, Яңавыл —
Кояш булып яна ул.
Яңавыл — яна ул,
Гел-гел алда бара ул!

Буә буйкайлары ямьле,
Буә сулары тәмле.
Буә суын эчкән кызлар
Нечкә билле, ак тәнле.

Кушымта.




Сакат таукайлары ташлы,
Оя кора бөркетләр.
Бөркетләрдәй кыю, данлы
Үсә бездә егетләр.

Кушымта.

Буә ярлары ак каен,
Сакат тауда — наратлар.
Нарат сынлы егетләргә
Биргесез безнең картлар.

Кушымта:

Яңавыл, Яңавыл —
Кояш булып яна ул.
Яңавыл — яна ул,
Гел-гел алда бара ул!



## ТУГАН ҖИРЕМ, БЕРГЕНӘМ

*Фәрит Суфияров сүзләре        Гөлнара Зыязова көе*

Чишмәләр күп, күлләр күп
Туган-үскән җиремдә.
Иркәли, назлый мине
Йомшак искән җиле дә.

Кушымта:

Туган җирем, бергенәм,
Кадерлисең, мин беләм.
Гомер язымны бизи
Бәхетле язмыш белән.
Яңавылым, бергенәм,
Кадерлисең, мин беләм.
Гомер язымны бизи
Бәхетле язмыш белән.

Кырларында иген үсә,
Аккошлар күлгә төшә.
Туган җирем, Яңавылым,
Матур җыр булып күчә.

Кушымта.

Йөрәгем белән тоямын
Туган җирнең җылысын.
Якты таңнар алып килә
Шатлыгымның зурысын.

Кушымта.


Чиш – мә – ләр күп, күл – ләр күп
ту – ган-ус – кән җи – рем – дә. Ир – кә – ли,
наз – лый ми – не йом – шак ис – кән җи – ле
дә. Ту – ган җи – рем, бер ге – нәм,
ка – дер – ли – сең, мин бе – ләм.
Го – мер я – зым – ны би – зи бә – хет – ле яз – мыш бе – лән.
Я – ңа – вы – лым, бер – ге – нәм, ка – дер – ли – сең, мин бе – ләм,
Го – мер я – зым – ны би – зи бә – хет – ле яз – мыш бе – лән.

## БИРМӘС ИДЕМ БҮТӘНГӘ

*Әкълимә Саяпова сүзләре* *Гөлнара Зыязова көе*




Икебез дә яшь булганбыз, иркәм,
Белмәгәнбез сөю кадерен.
Яшьлек үтте, минем күңелемдә
Сөю генә калды, кадерлем.

Еллар үтте. Күңел нидер көтте,
Минем өмет — һаман син бит ул.
Әгәр күңелемдә син булмасаң,
Яшәү яме юкка тиң бит ул.

Без яраткан язлар килер кебек,
Гөлләр үсәр кебек түтәлдә...
Хыялларым чынга аша калса,
Юк, юк, бирмәс идем бүтәнгә.

## СИНЕ ЮКСЫНАМ

*Фәрит Суфияров сүзләре* — *Өлфәт Хәмидуллин көе*




Тәрәзәңә үр(е)леп гөлләр үсә,
Гөлләреңә сулар сибәрсең.
Күгәрченнәр кебек, серләреңне,
Эй, чибәрем, кемгә сөйләрсең.

Иртә-кичен өй турыңнан узам,
Карашымны минем сизмисең.
Кара күзләреңне төбәп ялгыз,
Эй, чибәрем, кемне күзлисең.

Күк өстендә янган йолдызлар күп,
Барысы да миңа ят сыман.
Уйларымнан чыгып торганың юк,
Эй, чибәрем, сине юксынам.

## ЯШЬЛЕК ХАТИРӘСЕ

*Фәрит Суфияров сүзләре* — *Кәрам Әһлиуллин көе*

Юлларыма яңа юл кушыла,
Елларыма еллар өстәлә *.
Туган көннең шаулы тантанасы
Бергә җыя безне өстәлгә.

* Соңгы өч юл икешәр тапкыр кабатлана.




Маңгай бөдрәләрен сирәкләтеп,
Чәчләремне еллар агарта.
Табыннарда безнең җырлаган җыр
Яшьлек хатирәсен яңарта.

Узган еллар төшкә генә керә,
Сагышына сала күзләр дә.
Күктә янган соңгы йолдыз сыман,
Яшьлек дәрте калды күзләрдә.

## ӨЛӘШЕП БИРӘСЕМ БАР

*Фәрит Суфияров сүзләре* *Кәрам Әхлиуллин көе*

Җырланачак җырларым бар,
Сөясе ярларым бар.
Юшкыннар булып утырган
Күңелем зарлары бар.




Юлымда очрый киртәләр —
Сүтәсем, үтәсем бар.
Кышкы салкыннар өшетә,
Язларны көтәсем бар.

Эчәсе чишмә суларым,
Сөрәсе җирләрем бар.
Хезмәт шатлыгы кичерәм,
Тормышта кирәгем бар.

Йөрәгемне ялкын итеп,
Үрләргә менәсем бар.
Шатлыгымны кешеләргә
Өләшеп бирәсем бар.

39168-28193

ЦБС Янаульского
района Баш. АССР
абонемент

## ЭЧТӘЛЕК

Иҗат офыклары киңәя. *Фәрит Суфияров* . . . . . . . . . . 3

## ШИГЫРЬЛӘР

**Фәрит Суфияров**

Оран салам . . . . . . . . . . . . . . . 6
«Урал урманнарын кистем...» . . . . . . . . . . . 7
Язмыш белән алышам . . . . . . . . . . . . . 7
Юл йөреп гомер уза . . . . . . . . . . . . . 8
Әйтерсең лә, берни булмаган . . . . . . . . . . 8
Без адаштык . . . . . . . . . . . . . . . 9
Көнчелләр күп . . . . . . . . . . . . . . 10
Җыр кала . . . . . . . . . . . . . . . 10
Тансык язым . . . . . . . . . . . . . . 11
Яңавыл . . . . . . . . . . . . . . . . 11

**Әкълимә Саяпова**

Башкортстан . . . . . . . . . . . . . . 13
Акыл китер безгә, Яңа ел . . . . . . . . . . . 13
Җиңү бәйрәме . . . . . . . . . . . . . . 14
Яңа язда . . . . . . . . . . . . . . . 15
Узыша яшьлек белән . . . . . . . . . . . . 15
Йортымны туздырып куймасын . . . . . . . . . . 16
Соң, дип тормас . . . . . . . . . . . . . 16

**Қасыйм Гайданов**

И, туган ил . . . . . . . . . . . . . . 17
Сугыштан соң . . . . . . . . . . . . . . 17
Үткән юлларым . . . . . . . . . . . . . . 18
Шагыйрь . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Сабый хаты . . . . . . . . . . . . . . . 20
Җырлар әйтә . . . . . . . . . . . . . . 21
Сакат тауларында . . . . . . . . . . . . . 22

**Рәфис Мөхәммәтдинов**

Язмышлар түгел уен... . . . . . . . . . . . . 23
Болында . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Таш бәгырь . . . . . . . . . . . . . . . 24
Юк, китәсем килми! . . . . . . . . . . . . 24
Қайту . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Қыш һәм чәчәкләр . . . . . . . . . . . . . 25

Үз гөлем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
«Тәрәзәмә таш аталар...» . . . . . . . . . . . . . . 25
Көзге таңда . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26

**Сания Вәлиуллина**

Чишмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Ничек хәлегез? . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Корыч буынга . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Медсестра апага . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Кем тигән? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30

**Таһир Шәрипов**

Туган ягым . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Чәчәкләр бүләк итәм . . . . . . . . . . . . . . . 32
Отчет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Хөрмәтулла . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Салих абзый . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
«Муллык» сере . . . . . . . . . . . . . . . . . 34

**Яхъя Йосыпов**

Һәйкәлләрдән аваз салалар . . . . . . . . . . . . 36
Җиңү таңы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Бәйрәм килә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Күңелләрдә мәңге саклана . . . . . . . . . . . . 38
Дан тараткан . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Укытучы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39

**Венера Каһирова**

Бар дөньяны килә кочасым . . . . . . . . . . . . 40
Туган җирем — Башкортстан . . . . . . . . . . . 40
Гафу ит син мине! . . . . . . . . . . . . . . . 41
Кит, дисеңме? . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Иртә белән бакчаларда . . . . . . . . . . . . . 42
Безнең әнкәй . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Фәрештәләр дәвасы . . . . . . . . . . . . . . . 43
«Табигатьтән изгеләр дә туа...» . . . . . . . . . . 43

**Сәгыйть Нурмөхәммәтов**

Җәйге тын кичләрдә . . . . . . . . . . . . . . . 44
Яшьлегем таңы . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Ялгыз калдым . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
«Аланнарда печән чабам...» . . . . . . . . . . . . 45
Сандугач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46

Әгәр чыксам басу сукмагына . . . . . . . . . . . . 46
Бәхет турында . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Кырпак кар . . . . . . . . . . . . . . . . . 48

## ХИКӘЯЛӘР

**Инсур Шәнгәрәев**

Ходай хөкеме . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Бер-берсенә охшаган . . . . . . . . . . . . . 52

**Кәүсәрия Шәфыйкова**

Туган көн . . . . . . . . . . . . . . . . . 55

**Камил Гәрәев**

Штаттан кыскартты . . . . . . . . . . . . . 58
Закуска . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59

**Әмир Фәтыйхов**

Гарәфә кич туган өмет . . . . . . . . . . . . 60

**Данис Садриев**

Алтын туйдан соң . . . . . . . . . . . . . . 65
Авыр сорау . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Дөрес шикләнү . . . . . . . . . . . . . . . 66
Яхшы сүз яманлыгы . . . . . . . . . . . . . 66
Тиз эчсәң . . . . . . . . . . . . . . . . . 66

## ЖЫРЛАР

**Әнис Шәймәрдәнов**

Яңавыл *(С. Нурмөхәммәтов)* . . . . . . . . . . . 68
Яңавыл — яна ул! *(Г. Әмири)* . . . . . . . . . . 69

**Гөлнара Зыязова**

Туган җирем, бергенәм *(Ф. Суфияров)* . . . . . . . 71
Бирмәс идем бүтәнгә *(Ә. Саянова)* . . . . . . . . 73

**Өлфәт Хәмидуллин**

Сине юксынам *(Ф. Суфияров)* . . . . . . . . . . . 74

**Кәрам Әһлиуллин**

Яшьлек хатирәсе *(Ф. Суфияров)* . . . . . . . . . . 74
**Өләшеп бирәсем бар (Ф. Суфияров)** . . . . . . . . 75

Литературно-художественное издание

**БУИНСКИЕ БЕРЕЗЫ**

**Стихи, рассказы, песни**

*(на татарском языке)*

Мөхәррире *Д. Г. Морзакаева*
Рәссамы *Ә. Р. Хәбибуллин*
Бизәлеш мөхәррире *Р. М. Рамазанов*
Техник мөхәррире *Н. Я. Зарипова*
Корректоры *З. М. Адыева*

Җыярга бирелде 4.09.95. Басарга кул куелды 24.01.96. Кәгазь форматы $60 \times 84^1/_{16}$. Тип. кәгазе № 1. Әдәби гарнитура. Калку ысул белән басылды. Шартлы басма таб. 4,65. Тиражы 5000 данә. Заказ 1046. Бәясе ирекле.

Яңавыл язучылар оешмасы.

Уфа полиграфия комбинаты. 450001, Уфа, Октябрь проспекты, 2.

2400 —

